Закир Шакиров

# РӘСЕМЛЕ ҖӘГЪРАФИЯ



Электрон басма
“Гыйлем”
2016

# Кереш сүз урынына

Татар теле — фән теле. Моның шулай булуын 1914 елда басылып чыккан «Рәсемле җәгъръфия» дәреслеге дә исбатлый шикелле. Закир Шакиров исемле мөгаллим әзерләгән бу дәреслек, чыннан да, иллюстрацияләргә бай, җиңел, укырга рәхәт телле уку әсбабы булган. Әлбәттә, анда китерелгән мәгълүмат бүген инде хакыйкатьтән бик ерак тора, әмма аның кадере, бәлки, шундадыр да: 100 ел элек кешеләр үз җәмгыятьләрен, илләрен ничек өйрәнгәннәр, күзаллаганнар, аңлаганнар? Русия империясенең никадәр зур булуын төшенер өчен туган ил географиясенә багышланган бүлекләрне укып чыгу да җитә.

Әлеге кыйммәтле фәнни-тарихи чыганак география белән кызыксынучыларга һәм, алардан битәр, тарих сөючеләргә файдалы бер китап булыр дип өметләнәбез. «Гыйльми мирас» проекты шундый фәнни мирасыбызны чак кына яңарту, халыкка җиткерү максатын куя. «Рәсемле җәгъръфия» бу максатка яраклы рәвештә, хәзерге кирилл имласына күчерелеп, электрон басма итеп нәшер ителгән беренче китабыбыз булды. Бу эшне Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Шәрекъне өйрәнү институты талибәсе Рәхимә Шиһапова башкарып чыкты.

Иске имлада оригиналның электрон версиясен интернетка элгән өчен darul-kutub.com сайтына рәхмәтлебез.

*Бу китапны йөкләп алучыларга рәхмәт белән, «Гыйлем» мөхәррияте*

http://giylem.tatar

Кирилл имласына күчереп, басуга әзерләү — Рәхимә Шиһапова

Тышлык — Даниль Әхмәтшин

Мөхәррир — Айдар Шәйхин

Creative Commons Attribution 4.0

*Әлеге электрон басмага Creative Commons BY лицензиясе бирелә. Димәк, аны ирекле рәвештә тарату, төзәтү, үзгәртү һәм шуның нигезендә башка әсәр иҗат итү өчен авторлыкны күрсәтү генә таләп ителә.*

Мөгаллим Закир Шакиров

Кыскартылган дәреслек

# Рәсемле җәгъръфия

1 нче кисәк мәктәпләр өчен



Нәшер итүче: Шәмсетдин Хөсәенов

Казань


Электро-типография “Умид”

1914

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахим

## §1 — Безнең сыйныф

Без хәзер мәктәп эчендә; аның бүлмәләре күп. Алгы бүлмәсендә без тышкы киемнәребезне салып калдырабыз, аш бүлмәсендә аш ашыйбыз, йокы бүлмәсендә йоклыйбыз. Бер бүлмәсендә укыйбыз, язабыз һәм хисап мәсъәләләре чишәбез; көйләп шигырьләр, мөнәҗәтләр, бәетләр укыйбыз.



Сыйныф рәсеме

Без сыйныфта парталарга (көрсиләргә) утырабыз. Парталар алдында мөгаллим өстәле, сыйныф тактасы, болардан башка тагын сыйныфта безнең күзебезгә идән, түшәм, пич, урындык, шкаф һәм дүрт стена күренәдер. Ул стеналарның икесе мәктәпнең буе, икесе иңе була. Аларда ишек һәм тәрәзәләр ясалган, һәм эчке якларына рәсемнәр, карталар эленгән.

## §2 — Мәйдан (мисәхә)

Бер урында бер нәрсә булса, ул урында икенче нәрсәгә торырга туры килми; аңа ул нәрсә белән янәшә торырга яки аның өстендә ятырга, яки өстендә торырга туры килә. Безнең күзебезгә күренә торган һәрбер нәрсәнең үзе торган кадәр каплаган үз урыны була.

Сыйныфтагы әйберләрнең барысының да үз урыны бар. Менә бу китапның урыны мәктәпнең сыйныф бүлмәсендәге көрси өстендә, сыйныф бүлмәсенең урыны, мәктәп эчендә, мәктәпнең урыны аны салыр өчен бүлеп алынган җир кисәгендәдер. Әйберләрнең үзләре сыйган кадәр каплаган урыннары "мисәхә" — мәйдан дип атала.


## §3— Әйберләр һәм рәсем

Сыйныф бүлмәсендә без әллә ничә төрле әйбер күрәбез, мәсәлән: китап, кара савыты, тәрәзә, ишек, сыйныф тактасы һәм өстәл, счет, көрсиләр һәм башкалар. Шул ук нәрсәләрне без картиналарда да күрәбез; ләкин аерма бар: сыйныф эчендә без әйберләрнең үзләрен күрәбез; ә картиналарда ул әйберләрнең нәкъ үзләрен түгел, рәвешләрен генә күрәбез. Һәр күзгә күренгән нәрсәнең озынлыгы, киңлеге, биеклеге читтән караганда күзгә ничек булып күренсә, шулай итеп аның рәвешен кәгазьгә яки тактага сызып күрсәтергә була. Әйбернең менә шулай итеп сызылган рәвешенә аның "рәсеме" диелә.


Китап рәсеме

## §4— План

Без китапны сыйныф тактасына куеп, һәр ягыннан акбур белән сызып аны тактадан алсак, такта өстендә дүртпочмаклы бер сызык күрәбез. Бу сызык безнең такта өстенә куеп тирә ягыннан акбур белән сызган китабыбызның урынының мисәхәсен күрсәтә. Бу дүртпочмаклы сызыкның буе, иңе шул китапның буеның, иңенең нәкъ үзе була. Менә шушы дүртпочмаклы сызык шул китапның "планы[1]" була.



Китапның планы

Кара савытын кәгазь өстенә куеп, һәр ягыннан карандаш каләм белән сызгач, кәгазь өстеннән алсак, кәгазь өстендә түгәрәк бер сызык күрәбез; бу сызык безгә кара савытының кәгазь өстендә

[1] өлгесе

күпме урын алганлыгын — мисәхәсен күрсәтә. Бу түгәрәк сызык кара савытының планы була.

Кара савыт, китап шикелле кечкенә әйберләрнең планнарын тактага да, кәгазьгә дә сыйдырырга мөмкин. Өй, йорт урыны, урам, мәчет, басу кебек зур нәрсәләрнең планнарын үзләре зурлыкларындагы кәгазьләргә сызып ясап булмый. Чөнки аларның үз зурлыкларын сызарга андый зур кәгазь юк. Булган чагында да йөртергә уңайсыз булыр иде. Шуңа күрә мондый зур әйберләрнең планнары чын зурлыкларыннан берничә кат киметеп төшерелә. Әгәр дә план алыначак нәрсә яки урын бик зур булса, ул чагында бер дюйм ун яки йөз, сажень, бер чакрым, хәтта йөз чакрым урынында йөртелә. Зур нәрсәләрнең планнарын алганда, мәсәлән, сыйныфның планын алмакчы булсак, иң алдан бер үлчәү белән аның буен, иңен үлчибез. Аршин белән үлчәгәннән соң, сыйныфның буе 12 аршин, иңе 8 аршин булсын. Аннан соң бер кәгазь алып дүрт почмаклы сызык сызабыз. Моны сызганда чынлыктагыча зурлыкта сызар идек — кәгазьгә сыймый; шуңа күрә киметеп, буен 12 дюйм, иңен 8 дюйм итеп сызабыз. Менә шул дүртпочмаклы сызык безнең сыйныфның планы була.





Сыйныф планы
1 такта, 2 мөгаллим өстәле, 3 көрсиләр, 4 пич, 5 шкаф, 6 ишек, 7 тәрәзәләр.
Масштаб : бер дюймда 2 аршин.

## §5— Микъяс — масштаб

Әйберләрнең планын төшергәндә, зур үлчәүләр урынына йөртелә торган үлчәүләргә “микъяс һәм масштаб” дип әйтәләр.

Масштабка карап планнан төшерелгән нәрсәнең чынлыктагы зурлыгыннан ничә кат кечерәйтелеп төшерелгәнен белеп була. Без югарыда сөйләгән мисалда сыйныфны чынлыктагы үлчәвеннән 28 кат кечерәйттек.

Әгәр дә безгә берәр нәрсәнең планы һәм масштабы бирелсә, без шул планга карап аның чынлыктагы буеның, иңенең зурлыкларын беләбез. Мәсәлән: безнең кулыбызда өй планы булып, ул өйнең планын алганда, бер сажень урынына бер дюйм алынган булса, бу өйнең планының буен дюйм белән үлчибез. Үлчәгәч планның буе 15 дюйм булса, моннан беләбез планны алган өйнең буе 15 сажень икәнен. Сыйныф бүлмәсе шикелле мәктәпнең һәр бүлмәсенең планын төшереп була. Бөтен өйнең планын алганда да, өйдәге бүлмәләрнең планнары масштаб буенча сызылыр. Ләкин бөтен өй планын төшергәндә, масштабны тагын да кечкенәрәк үлчәүдән алырбыз. Ике, өч һәм күбрәк саженьнәр урынына бер дюйм йөртербез.




**Мәктәп планы**

1 хезмәтче бүлмәсе; 2, 3 мөгаллим бүлмәсе; 4 намаз бүлмәсе; 5 өй алды; 6 сыйныф; 7 ашханә вә аш бүлмәсе; 8 йокы бүлмәсе; 9 кладовкалар (михзәнәләр).

Масштаб: бер дюйм 4 аршин.

## §6— Мәктәпнең усадьбасы

Кайсыбер мәктәпнең ишек алды, ишек алдының бер читендә, бәрәнге, кәбестә вә агач бакчалары була. Ишек алдында амбар, келәт, утын сарае кебек каралтылар була. Мәктәп салынган йорт урыны вә анда бина ителгән каралтыларның барысына бер юлы мәктәпнең усадьбасы диләр. Әгәр дә мәктәп усадьбасының планын төшермәкче булсак, иң әүвәл мәктәпне вә башка бакчаларны, өй алдын, аларның арасындагы ярыкларны үлчәп масштаб буенча бер кәгазьгә сызабыз. Монда масштабны бик вак киметергә. Мәсәлән: 10, 20, 50 саженьны бер дюйм исәпләргә кирәк. Бу усадьба планында мәктәпнең вә башка каралтыларның планнарын бик ачык күрсәтеп булмый. План күпме зур булса, аның кисәкләре шулкадәр кечкенә була.

## §7 — Күршеләр, авыл

Мәктәп усадьбасы белән янәшә авыл кешеләренең усадьбалары тезелгән. Һәр усадьбаның үзенең махсус җире, каралтылары була. Усадьбада берсе тора торган, икенчесе тормый торган каралты була. Тора торган каралты — өй, тормый торган каралты — амбар, келәт, сарай, лапас, мунча, әвен. Амбар, келәт кебек каралтыларда урылган иген саклана. Сарайга утын, печән куела, лапасларда йорт хайваннары торалар. Мунчада кешеләр юыналар, әвендә иген киптерәләр. Бәрәнге, кәбестә бакчасы, агач бакчасы — болар да усадьба дип саналалар. Кайсыбер усадьбаларның тоташ сөреп иген чәчә торган игенлеге, печәнлеге, мал йөри торган җире дә була. Әгәр дә өйләр бер рәтле төзелеп, салынып та игенлек, печәнлек җире шул өйләрнең тирәсендә аерым булса, аңа “авыл” диләр.

Әгәр дә авыл зур булса, анда мәктәп, мәчет, ике яки бер имам һәм бер мөәззин була. Авылда һәрбер сау, таза ир кеше һәр ел хәзинәгә бер микъдар акча бирә; ул акча хәзинәдән бөтен халыкның кирәгенә сарыф ителә: мәктәпләр бина ителеп, анда мөгаллимнәр куела, аларга вазифа бирелә, шифаханәләр салына, анда докторлар, фельдшерлар куела; күперләр, юллар төзекләндерелә.

## §8— Волость

Безнең мәктәп … волостендә. Волость зур вә кечкенә берничә авылдан гыйбәрәттер. Бөтен волостьнең планын да алырга була.


Волостьнең планын төшергәндә, һәрбер аерым авыллар, авылларның били торган җирләре, андагы таулар, чокырлар, күлләр, елгалар, инешләр, юлларның барысын да күрсәтергә кирәк. Волостьнең идарәсе шул волость кешеләренең үзара берничә елга сайлап куелган волостьневый старшина кулында. Волостьнең үзенә хас волостьневый правление исемендә мәхкәмәсе бар. Кайсыбер вак-төяк низаг вә мөрәҗәгатьләрне тикшереп хөкем итә торган волостьневый суд исемендә үзенә махсус судья да бар.

## §9 — Табигый вә сынагый (ясалма) хөдүд — чикләр

Янәшә усадьбалар, авыллар, күрше волостьлар бер берсенә терәлеп торалар. Менә бу усадьба вә авылларның, һәм волостьләрнең араларына "хөдүд- чик" диелә. Бу чикләр кайчак инеш, елга, күл кебек табигый була. Әгәр дә боларның араларында мондый табигый чик булмаса, болар арасына буразна, чокыр, канау казыйлар; мондый кешеләр тарафыннан ясалган чикләргә "сынагый хөдүд-чик" диләр. Бу чикләрне бер дә бозырга ярамый, бозучыга гаеп итеп җәза бирәләр.

## §10 — Офык вә аның җиһәтләре (яклары)


Без берәр тигез урында торган чакта, мәсәлән, киң бер басуның уртасында, шулвакыт безгә еракта күк җиргә терәлеп, икәү бергә кушылган шикелле булып күренә. Без кайсы якка карасак та, еракта, җир белән күк тирәсенең чикләнгән урынында, аның арт тарафында нәрсә барлыгы безгә беленмичә, безнең күзгә яшерен кала торган бер сызык күрәбез; менә шул безнең күзебезгә



Офык


күренгән түгәрәк сызыкны “офык даирәсе[2]” дип атыйлар.

Чынлыкта бу сызык монда юк. Югарырак урынга менеп карасак, ул түгәрәк сызык безнең күзгә тагын да зуррак булып, күк безгә, үзенең читләре белән офык сызыгына таянган гөмбәз вә киемсә булып күренәдер. Кояшның күк гөмбәзе буенча күренешен тәҗрибә итеп карасак, кояш көннең яртысы булган вакытта, офыктан югары һәрнәрсәдән биек булып күренә. Әгәр дә без шул вакытта йөзебез белән кояшка каршы булсак, алдыбызда офыкның җәнүб (көньяк) тарафы, артыбызда шәмәл (төньяк), сулыбызда шәрык, уң ягыбызда гареб тарафы була.




Шәрык, гареб, җәнүб һәм шәмәл тарафларына “асыл җиһәтләр” дип әйтәләр.

Офыкның асыл җиһәтләрдән башка яклары да бар: шәмәл шәркы, шәмәл гәрбе, җәнүб шәркы, җәнүб гәрбе җиһәтләредер. Офык дәирәсенең җиһәтләрен күзгә күренә торган нәрсәләрнең күләгәсе буенча тәҗрибә кылып та белергә була. Әгәр дә тип-тигез җир өстендә төз бер агач җиргә кадалынса, күкнең әүвәлге өлешендә аның күләгәсе кыскара, икенче өлешенә таба озая, күләгә тәмам кыскарып беткән вакытны көн уртасы, төшлек заманы дип әйтәләр.




Төшлек күләгәсе шәмәл ягына төшә, төшлек күләгәсеннән барлыкка килгән сызыкны төшлек сызыгы диләр. Әйбернең планын алганда, төшлек сызыгы ук кебек сызык белән күрсәтелә. Бу һәрнәрсәнең шәмәле югарыга таба булып, җәнүбе түбән, шәркы унда, гәрбе

---

[2] Дәирә – сызык, юл.

сулда булу кагыйдәсен күрсәтү өчендер.

## §11— Әйберләрнең урыннарын билгеләү

Әгәр дә без читтән мәктәп бинасына карасак, ул безнең алдыбызда күренә. Шул җирдән кузгалмыйча, без артыбыз белән борылсак, ул безнең артыбызда була. Уңга яки сулга карасак, безнең уңыбызда яки сулыбызда булыр. Әгәр дә мәктәп безнең шәмәл тарафта булса, без кайсы якка әйләнсәк тә, ул һаман шәмәл ягында кала. Моннан беленәдер: җир йөзендә булган һәрнәрсәнең урыны җирнең төп яклары белән тәгйин ителә, шуңа күрә, бер шәһәр турында сөйләсәләр, ул шәһәр безнең алдыбызда, артыбызда булсын – аның урынын, асыл җиһәтләргә карап, шәмәлдә, җәнүбтә, шәрыктә, гәребтә дип сөйлиләр.

Әйберләрнең яки урынның планын сызганда, шәмәл тарафын югары, җәнүб тарафын түбән, шәрык ягын уңда, гареб ягын сулда итеп төшерәләр.

## §12— Өязләр, губерналар


Безнең волость ... өязендәдер. Өяз күп җирдән һәм бик күп волостьләрдән ясаладыр. Өязебездәге тәртипләрне карап башкаручы – өяз башлыгы, яки исправник. Ул шул өяздәге шәһәрдә тора. Губерналар өязләргә караганда тагын да күбрәк җирдән, берничә өяздән ясалалар.

Без ... губернасында торабыз. Безнең губернада барысы ... өяз бар. Бөтен губернаны идәрә итүче губерна башлыгы – губернатор. Ул губернаның баш шәһәрендә тора. Безнең губернаның мәркәзе[3] ... шәһәре. Волостьнең, өязнең, губернаның җирен күрсәтә торган планга карта диеп әйтәләр.

## §13— Җирнең өсте


Безнең авылның (шәһәрнең) тирәсендә басулар, болыннар бар, боларның өслеге һәр урында бертөрле түгел: кайсы урыннары төз, кайсы урыннары зур су өстендәге дулкын сымак калку, иңкү, чокырлы-чакырлы, тигезсездер. Җир өстендәге төз, тигез урыннарга “тигезлек” диелә

[3] уртасы



Тигезлек

Тигез җирләрнең күбесендә гадәттә урман, болын, сөрә торган игенлек җирләре була. Тигезлекнең мондыйларына **ува** диләр.



Тау һәм вәдиләр (ике тау арасындагы чокырлар)

Җир өстендәге биек урыннарга “тау”, бер рәттән тезелеп киткән тауларга “тезелгән таулар”, тау өстендәге тигез урыннарга

(җәйләү) **йәйлә**, ике тау арасындагы киң озын чокырларга “вәди”, тауның тигез җиргә килеп тоташа торган сузык урыннарына “тау итәге”, тауларның иң биек җиренә тауның “түбәсе”, итәге белән түбәсе арасындагы авынкы урынына “тау бите, тау кабыргасы” дип әйтәләр.

Ике тау арасындагы тар җир кичәед[4]. Әгәр дә тигез җирдә ялгыз алан гына булса, урман, агачлык булмаса, аңа “степь”[5] диләр.




Степь

Степьләрдә вә урманлы тигез җирләрдә гадәттә күлләр, бик салмак кына ага торган елгалар була.

Җир йөзендә шундый тигезлекләр бар ки, анда су да, алан да, агач та – үсемлектән бернәрсә дә булмый. Кайда карасаң да – ялгыз ком да, ялангач ташлык кына була. Менә мондый тигезлеккә “чүл” диләр. Мондый чүлләр аркылы йөрү гаять читендер.



Вулкан

Кайсыбер тауларның түбәләреннән утлы ялкын, төтен яки сулы бу, аерылган ташлар йошкырып атылып тора. Мондый тауларны “утлы тау” яки “вулкан” дип әйтәләр.

Багде бер (кайбер) тауларның түбәләрендә һәрвакыт бер дә бетми торган карлар, бозлар була. Мондый тауларга “карлы таулар” диләр.

Карталарда тауларны кара буяу белән яки калынча сызык илә читкә тармакланып, чачакланып тора торган сызыклар белән сызып күрсәтәләр. Картада сызыклар

[4] кичү
[5] дала, ялан

булмаган урын тигезлекне күрсәтә. Карталарда иңкеш җирләр, увалар яшел төстә, йәйләләр ачык сары төстә күрсәтелә.

## §14— Җирнең катлавы

Әгәр дә җирне казып карасак күрәбез: күпме тирәнгә таба казысак безгә һәр урында ком, кызыл балчык, известь һәм төрле ташлар очрыйдыр. Җирдә була торган бу ком, кызыл балчык, [6]"җир җенсе" диелә. Җир алардан җыелган матдәләрнең катлаулары китап кәгазьләре кебек өсле өсле булып яталар. Бу катлауларның калынлыклары һәр җирдә бертөрле түгел: кайсыбер урыннарда берничә сажень юанлыгында була.

**Туфрак:** җирнең иң өске катлавына туфрак диелә. Бу туфрак бик әһәмиятледер. Бөтен үсемлекләр тамырларын шул туфракка җибәреп, аннан үзләренә кирәкле дүмне (дым, сок) алалар. Һәр туфрак ком, балчык, черегән үсемлекләрдән вә хайваннардан хасил була торган тирестән тора. Шушы тирес кайсы бер туфракларда күбрәк була. Туфракның үстерү һәм үстермәү хасияте шуңа карап йөри.

Комлы, кызыл балчыклы, кара балчыклы, сазламыклы "туфраклар" буладыр. Комлы туфрак ялгыз комнан гына гыйбарәт була. Мондый туфрак үзе аша суны бик тиз үткәрә һәм бик тиз кибә. Шуңа күрә коры һавада мондый туфракта үсемлек бик тиз корыйдыр. Иң әйбәт туфрак кара балчыклы туфрактыр. Кара балчыклы туфракта, бер дә тиресләмичә дә, иген бик яхшы уңадыр. Башка туфраклар өчен бик күп тиресләү кирәк. Әгәр дә тиресләнмәсә иген булмыйдыр.

## §15— Җирдән чыга торган мәгъдәннәр (металлар)

Без аның өстендә яши торган җирдән чыга торган матдәләр кешеләр өчен бик кирәкле нәрсәләр. Кешеләр җирдән гранит, мрамор, известь кебек бик күп төрле нәрсәләр казып чыгаралар, боларның һәркайсы биналар салуда истигмәл ителә (кулланыла). Мәсәлән: кызыл балчыктан кирпич сугалар, чүлмәк кебек төрле посудалар ясыйлар; җирдән чыга торган тоз ашарга тотыла; җир күмере ягу өчен истигмәл ителә (кулланыла).

---

[6] Тау нәуглары (төрләре), горная порода

Алтын, көмеш, тимер, бакыр, калай, кургаш вә башка төрле кыйммәтле ташлар да җирдән чыгадыр. Көмеш, тимер, бакыр кебек "мәгъдәннәр"[7] күбрәк башка нәрсәләр белән катнаш булалар. Аларны, җирдән чыгарылган табигый хәлләрендә "руда" диләр. Халис (тулы) мәгъдәнне аерыр өчен, аны махсус эшләнгән зур пичләрдә яндыралар. Мәгъдәнне аңарга катнашкан нәрсәләрдән чистарталар. Алтын белән платина башка нәрсәләрнең катнашуыннан башка чиста булып та табыла. Болар күбрәк балчык, комга катнашкан бөртекләр була. Бу алтын бөртекләрен балчыктан машина белән суда юып аералар, ком, балчык вә башка мәгъдәннәр су белән юылып агып китә. Алтын һәм платина авыр булганга күрә төптә калалар.

## §16— Су



Елга


Су җирнең астында да, эчендә дә бик күп. Суларның күбрәге күлләрдә, елгаларда, диңгезләрдәдер. Җир өстендә казан рәвешле һәр яктан биек кырый белән ихата ителгән (урап алынган) урыннарның су белән тулы булганнарына "күл" дип әйтәләр. Эчендә су ага торган озын чокырларны "елга" диеп әйтәләр. Елгалар, үзләренең суларын җир астыннан алып, һәр вакыт агып торалар. Елгаларның бик шәп тә, акрынлап та ага торганнары була. Эчендә елгалар агып, ул елгаларның суы белән тула торган чокырларның нәкъ уртасын елганың "үзәге" диләр.

Елганың чыккан җиренә "елганың башы"[8] , елганың диңгезгә, күлгә яки башка елгага барып кушыла торган җиренә елганың "тамагы"[9] диләр. Елганың ике кырыйларына "елганың яры яки сәхиле" дип әйтәләр. Елгаларның ярлары текә һәм сузык буладыр.

[7] Металлы - мәгъдәннәр
[8] Мәнбәгъ- исток
[9] Мәнсыб - устье



Зур елга



Текә яр

Бер елга икенче елгага килеп кушылса, елганың шул килеп кушыла торганына гарәпчә ”сәгде”[10] диләр.


Әгәр дә елганың ага торган ягына бер кеше алды белән карап торса, аның уң ягы шул елганың уңы, сул ягы елганың сул сәхиле буладыр.

Әгәр дә елга башын биек җирдән алса, аның агымы бик үткен була. Мондый елга үзенең агымында бик зур таш өемнәренә очрыйдыр. Ул ташлар су белән бергә агып, югары җирдән төшәләр дә, суның юлына утыралар. Су, шул ташлар турысына килеп җиткәч, ташларга бәрелеп болгана вә күбекләнә. Бу ташлар, елгаларның ага торган үзәкләренә төпләнеп, баскыч баскыч ясыйлар. Боларга “бусага, киселте”[11] диләр.



Елганың сузык, түбән яры

[10] Арык – приток
[11] Порог




Шарлавык

Әгәр дә елга үзенең агымында текә булып түбән ашалып төшкән урынына очраса, су аннан агып төшеп “шарлавык яки чүгермәк[12]” хасил итәдер.

## §17 — Диңгезләр

Зур су белән капланган киң мәйданга диңгез диелә. Диңгезләрнең бик зурлары бар, бер читеннән икенче читенә кадәр булган





киңлекләре берничә чакрымга сузыладыр. Диңгезләрнең зурларына “таш диңгез[13]” диләр.Таш диңгезләр диңгезләрдән иң зур, иң тирән

[12] Шәләлә – водопад




диңгезләр. Диңгезләрнең төбендә дә коры җир өстендә кебек тигезлек, таулык һәм вәдиләр[14] бар. Диңгез төбендә була торган таулар, суның өстенә калкып чыгып, коры җир мәйданы ясыйлар. Мондый су өстенә калкып чыккан җиргә “атау, утрау”[15] диләр.

Диңгезләрнең суы тозлы, ачы була, эчәргә ярамый, бик саф үтә күренә, кайсы бер урыннарда диңгез төбендә берничә сажень


Ташу


тирәнлектә ята торган әйберләр аерым ачык күренәләр. Диңгезнең өсте: көн аяз булса — зәңгәр, болытлы көндә — кара төстә була. Суы читтән күзгә кебек ялтырап тора. Җил,

[13] Бәхр мухит – океан


[14] Долины

[15] Остров (җәзира)

давыл булса, диңгезнең өсте бик куркыныч рәвештә дулкынланадыр. Диңгездә дулкын җилгә карап йөри: әгәр дә җил куәтле булса, дулкын да шулчаклы шәп була, хәтта дулкынның унбишәр сажень югарыга күтәрелгән чаклары да булгалый. Җилсез вакытта да диңгез өсте бик тын булмый. Диңгездә су тәүлегенә ике мәртәбә артып өскә күтәрелә, ике мәртәбә кайта. Суның өскә күтәрелүенә "ташу"[16] вә кайтуына "суның кайтуы"[17] диләр. Диңгезнң кайсыбер урыннарында су елга суы кебек төрле якка таба агып тора, моңа "агынты"[18] диләр.



Суның кайтуы – утрау



Кит

---

[16] Прилив
[17] Отлив
[18] Морское течение

Диңгездә төрле су хайваннары бик күп була, иң зурлары кит, морж, тюленьдыр.

Болардан башка: төрле балыклар, кыскычлар, киекләр, кортлар күптер.

Диңгезләрнең чите күбрәк тигезсез, керентеле чыгынтылы буладыр. Коры җир диңгез эченә озынаеп сузылып кереп торса, аңа “ ярты атау” диләр. Ярты атауның нәкъ очына борын диләр. Диңгезнең коры җир эченә кереп торган җиренә: әгәр дә зур булса “көрфәз”, кечкенә булса “лиман-бухта” диләр.

Ике диңгезнең бик тар гына булып кушылган җиренә “бугаз”, ике коры җирнең кушылган җиренә бик тар булса “бәрзәх (перешеек)” диләр.

## §18— Һава, җил, чык, кырау, томан, болыт, яңгыр, кар

Коры җирнең вә суның бөтен урынын бер төрле “җисем” чолгап алган. Без шул җисемне “һава” дип әйтәбез. Һава төссез, тонык, үтәдән үтә күренә торган бер нәрсәдер. Ул безнең бөтен атрафыбызны (якларыбызны) чолгап алган булса да, без аны сулап аның эчендә йөзеп йөрсәк тә, аны күзебез белән күрмибез, бары җил искән вакытта, һаваның кисәкләренең йөзебезгә килеп тигәнен генә сизәбез. Һава шулай бөтен җир өстен чолгаган булса да, һәр урында бертөрле түгелдер.

Әгәр дә бер кеше тау башына менсә, ул анда һаваның түбәнгә караганда салкынрак һәм сулау өчен авыррак булганын сизә. Бу шунлыктан килә: биек җирләрдә һава түбән җирләргә караганда сыегырактыр. Сулау өчен сыек һава бик авыр була. Сыек һава кояшның кызуы белән дә бик аз гына җылына, шуңа күрә кайсыбер тауларның башларында кышлыкта гына түгел, хәтта кызу вә эссе җәй уртасында да карлар була.

**Җил**: һава бик сирәк вакытта гына тик тора. Юкса күп чагында ул кайсы якка булса да бер тарафка исеп, кузгалып тора. Кояш җирнең бөтен урынын бертөрле җылытмый, кайсы якта кояшның җылысы күп, кайсы якта әздер. Кояшның җылысы күп булган якның һавасы җылы, җылысы әз тигән якның һавасы салкын була. Салкын һава, җылы һавага караганда куерак һәм авырырак, җылы һава сыегырак һәм җиңелерәк була. Салкын һава авыр булганга

күрә, югарыга күтәрелеп киткән җылы һава урынына түбән төшәдер. Җылы һава җиңел булганлыктан, югарыга күтәрелә дә, салкын һава килгән тарафка таба агып барадыр. Кыш көнендә ишекне ачсак күрәбез: тыштан салкын һава ишекнең астыннан керә, шул ук вакытта җылы һава ишекнең өстеннән тышка чыгадыр. Бу безгә җылы һава белән салкын һаваның йөрүен бик ачык күрсәтәдер. Шулай җылы һава урынына салкын һава, салкын һава урынына җылы һава килеп, бертуктамый һава йөреп тора. Эссе яклардагы җылы һава, салкын тарафларга, салкын тарафлардагы салкын һава җылы тарафларга агып исеп барадыр. Һаваның шул йөрүенә без "җил" дибез.

**Чык**: чынаяк тәрилкәсенә әзрәк су салып бүлмәгә яки ишек алдына куябыз: бер ике көн торганнан соң, бу тәрилкәдә су булмас, андагы бар су югалып бетәр. Бу су кайда киткән? Бу су парга "бу"га әйләнеп һавага очкан. Диңгезләр, күлләр һәм елгаларның да сулары буланып (парланып) һавага күтәреләләр.

Һавада сулы пар бар. Моны яхшырак белер өчен шундый бер тәҗрибә ясыйк: җылы бүлмәгә салкын бер стакан кертеп өстәл өстенә куйсак, берничә минуттан соң бу стаканның тирәсенә су тамчылыры капланыр. Бу тамчылар кайдан килгән? Вә ничек җыелганнар? — Һавадагы сулы парлар салкын стаканның өстенә тиеп суыкланып, куеланып вак тамчыларга әйләнгәннәр. Шулай ук җирдә дә көндез күтәрелгән сулы парлар, кич белән һавага караганда салкынрак булган җиргә, үсемлекләргә тияләр дә, вак тамчыларга әйләнәләр. Менә шул тамчыларга "чык" диләр.

**Кырау**: көз көннәрендә җир өстендәге нәрсәләр бигрәк тә суыналар, шунлыктан да һавадагы әлеге сулы парлар салкын җиргә тияләр дә карланалар. Ягни вак кар бөртекләре хасил буладыр. Бу кар бөртекләре бөтен үсемлекләрнең өстен каплыйдыр. Без шул кар бөртекләренә "кырау" дибез.

**Томан**: сулы пар җылы һавадан салкынрак һава арасына барып керсә, ул анда куеланып, вак кына су бөртекләре кебек булып күзгә күренә, без моны "томан" дибез.

**Болыт**: әгәр дә томан югарыга күтәрелеп һавада йөзеп йөрсә, без моңа "болыт" дибез.

**Яңгыр**: болыт белән томан икесе бер нәрсәдер. Түбәсендә болыт күренә торган тауның башына менгән кеше, тау башында үзен томан эчендә күрәдер. Әгәр дә югарыда аның эчендә болыт агып йөри торган һава салкынайса, кечкенә су бөртекләре зураеп, бер-берсебелән кушылып су тамчылары булалар. Бу су тамчылары җиңелерәк чакларында һавда йөзеп йөриләр, авыраяя төшкәчтен тамчылар җиргә төшәләр, без моңа "яңгыр" дибез.

**Боз**: бу тамчылар җиргә төшкәндә һаваның салкынрак катлавына туры килсәләр, җәйлектә булса, туңып катып җиргә йомры боз кисәкләре, кышлыкта булса — төрле матур рәвешләрдә йомшак кар булып төшәләр.



Карлар рәсеме

## §19 — Әклим (климат)

Кояш бөтен Җир йөзен һәр көнне яктырта һәм җылыта. Яктылык, җылылык үсемлекләр, хайваннар, кешеләр өчен иң кирәкле нәрсәләрдәндер. Әгәр дә җир йөзе һәрвакыт салкын һәм караңгы булса, җансыз чүл хәлендә күренер иде. Диккать белән каралса, күрелер иде: кояш никадәр югары булса, шулкадәр аның эсселеге, кызулыгы күп була. Җәй көне, башка вакытларга караганда кояш югарырак күренәдер.

Шунлыктан җәйлектә җир өсте башка вакытларга караганда кызуырак була. Кышлыкта хәтта көн уртасында да кояш бик түбән күренә, шуңа күрә җир өсте кыш көне әз җылына һәм суык була. Җир йөзендә кояшның нәкъ түбә өстендә генә тора торган урыннары да бар, мондый җирләрдә кыш бөтенләй булмый, бөтен

ел әйләнәсендә анда көннәр кызу, эссе була. Бу якларга “эссе як[19]” диләр. Моның киресенчә, көн уртасында кояш күккә күтәрелми торган урыннар да бар. Мондый җирләрдә ел әйләнәсендә көннәр салкын була. Бу җирләргә “салкын як[20]” диләр.


Кайсы бер җирләрдә көннәр артык җылы да салкын да булмый, уртача гына була. Мәсәлән бездә кояш җирне уртача гына җылыта, шуңа күрә безнең якны “һавасы әклими[21]” , “уртача як” диләр.

Кояшның эсселеге җирне генә түгел, һаваны да җылыта, эссе җирләрдә һаваның җылынуы күбрәк, салкын, суык урыннарда әзрәк була. Диңгезләргә якынрак урыннарның һавасы, аңарда сулы пар күбрәк булганга күрә юеш, диңгезләрдән, зур елгалардан ерак урыннарның һавасы, анда сулы пар аз булганга күрә коры була. Һаваның җылылык, салкынлык, юешлек хасиятләренә “әклим[22]” диелә. Җылылыкның дәрәҗәсенә карап әклим: җылы, эссе, уртача, салкын, юеш, коры була.

## §20 — Күрраи мүҗәссәмә, күрраи мүсәттахә (глобус)

Җирне борынгы заманда кешеләр яссы, тигез, чиге-кырые бар дип

уйлаганнар. Аларның уйларынча, әгәр дә бер кеше кайсы тарафка булса да бер якка таба китсә, бара торгачтын ул бик зур бер диңгезгә барып җитә, әгәр дә диңгездә дә шул бара торган ягына таба китсә, берникадәр баргач диңгезнең читенә барып җитә. Аның ул як чите төпсез бер урын; анда бөтен дөньядагы диңгезләрнең сулары бөтерелеп, төпкә агып төшеп китәдер. Борынгы халыклар, диңгезнең шул төпсез җиренә барып төшербез диеп, диңгезләрдә бик күп сәяхәт итмәгән. Ләкин соңыннан галимнәр тикшереп белгәннәр: җир борынгылар уйлаганча яссы түгел икән, бәлки резинка туп кебек түгәрәк ул; һәрбер түгәрәк нәрсәнең чите-кырые булмаган кебек, җирнең дә чите-кырые юктыр.



Күрраи мүҗәссәмә (глобус)

[19] Мәнтыка хәрра (гар.) эссе урын
[20] Мантыка бәридә – салкын урын
[21] Мәнтыка мүгтәдилә – уртача урын
[22] Климат


Җирнең чынлап та ничек икәнен белү өчен, корыда да, суда да сәяхәт итеп, бөтен җирне әйләнеп йөреп, үзләренең башта чыгып киткән урыннарына кире әйләнеп кайталар. Кайтканда башта чыгып киткән якларыннан түгел, икенче тарафтан: кояш батышына таба киткән кеше, кояш чыгышы ягыннан әйләнеп кайтмыштыр.

Менә шуннан соң җирнең түгәрәк булуында һичберәүнең шөбһәсе калмаган. Бу көндә инде дөньяны әйләнеп кайту гади бер эштер. Җирнең әйләнәсенең ераклыгы бик дөрес итеп үлчәнгән. Җирнең әйләнәсе 37000 чакрым икәне мәгълүмдыр (билгеледер). Җирнең рәвешен күрсәтер өчен кәгазьдән яки агачтан ясалган түгәрәк шарны "күрраи мүҗәссәмә"[23] диләр.

Бөтен җирне ике түгәрәк сызык эчендә күрсәтә торган кәгазьгә "күрраи мүсәттахә"[24] диләр.

Йомры, түгәрәк нәрсәнең һәръягын берьюлы күреп булмый. Шарның яртысы гына күренә; шунлыктан җирнең бөтен харитасын сызганда, ике түгәрәк сызык эчендә төшерәләр. Түгәрәк сызыкның берсе эчендә җир шарының бер ягын, сызыкның икенчесе эчендә — шарның икенче ягын күрәбез.

## §21— Коры җирнең вә суларның бүленүләре




1 — Азия, 2 — Африка, 3 — шимәли (төньяк) Америка, 4 — җәнүби (көньяк) Америка, 5 — Яврупа, 6 - Австралия

Күрраи мүҗәссәмәгә яки күрраи мүсәттахәгә карасак, җир өстендә коры җиргә караганда суларның күбрәк булганын күрәбез. Су җир өстенең дүрт өлештән өч өлеше чаклыдыр. Бөтен җирнең дүрт өлешеннән бары бер генә өлеше коры җирдер. Калганы сулар белән капланганды́р. Коры җир судан өч зур кисәк булып чыгып тора, шул зур кисәкләргә "коры җир"[25] диләр. Иң зур коры җир кояш чыгышындагысы булып, Яврупа, Азия, Африка исемнәрендә өчкә бүленәдер. Икенчесе кояш баешы ягындагы кара җир яки Яңа дөнья булып Америка исемендәдер.

[23] Җир шары, глобус
[24] Полушария
[25] Материк

Өченче коры җир дөньяның бишенче кисәге, моңа җәнүби (көньяк) коры җир, яки иң яңа дөнья дип әйтәләр. Менә шулай бөтен җир биш кисәккә бүленә: Яврупа, Азия, Африка, Америка, Австралия. Бу кисәкләрнең иң зурысы Азия булып, Яврупадан дүрт өлеш зурдыр.

## §22— Сулар да коры җир кебек биш кисәккә бүленәләр:



1) Олуг мохит диңгезе, 2) Атласи диңгезе, 3) Һинд диңгезе, 4) Җәнүби (көньяк) боз диңгезе, 5) Шәмәли (төньяк) боз диңгезе.

1) Олуг мохит диңгезе (Азия белән Америка арасында) зурлыкта иң беренчедер. Бу диңгез бөтен коры җирдән бер ярым кадәр зурдыр.
2) Атласи диңгезе (Аурупа белән Африка, Америка арасында).
3) Һинд диңгезе (Африка, Америка кытгаләренең (материкларының) җәнүбендә)
4) Шәмәли боз диңгезе (Төньяк боз океаны, Аурупа, Азия, Америка арасында).
5) Җәнүби боз диңгезе (Көньяк океан, Африка, Америка кыйтгаларының җәнүбендә).

## §23— Кешеләрнең нәселләре

Җир ничаклы зур булса да, аның өстенең һәр җиренә кешеләр таралган. Җир йөзендә барысы 1,500 мильон кадәр кеше хисап ителә. Бөтен җир йөзендәге кешеләр тәннәренең төсләренә, йөзләренең сурәт вә кыяфәтләренә, сөйләшә торган телләренә күрә бик күп төрле җенес вә кавемнәргә аерылалар.

Тәннәренең төсләренә, йөз вә кыяфәтләренә күрә җир йөзендәге кешеләр дүрткә аерылалар.

**Ак җенес:** (кавказ ыругы) боларның тәннәре вә йөзләре ак; күзләре кара, зәңгәр; чәчләре йомшак. Борынгыдан бирле Яврупада, Азиянең җәнүб гаребендә (көньяк көнбатышында), Африканың

шәмәл шәркысендә (төньяк көнчыгышында) яшиләр. Бу нәселнең халкы бик күп булып, берничә олы, кечкенә кавемнәргә аерылалар: руслар, немецлар, англичаннар, итальяннар, французлар, испаниялылар, гәрәпләр, яһүдиләр, әрмәннәр.



Ак җенес — кавказ ыругы

**Сары җенес:** боларның төсләре сары; маңгайлары киң; яңак сөякләре чыгынты; күзләре кечкенә, кысык; борыннары яссы; чәчләре калын вә каты. Кытайлар, японнар, финнар, татарлар, башкортлар, кыргызлар бу нәселдәндер.



Сары җенес

**Кызыл җенес:** боларның төсләре бакыр сымак кызыл. Болар Америкада яшиләр, нәселләре әзәеп бетеп бара.



Кызыл җенес

**Кара җенес:** боларның тәннәренең төсләре кара; чәчләре кара һәм бөтеренке; иреннәре калын; күзләре зур. Болар Африкада, Австралиядә яшиләр.



Кара җенес

## §24— Мәдәнилек (цивилизованность), бәдәвилек (первобытность), вәхшилек (дикость)

Җир йөзендәге кешеләр, үзләренең дөньяда көн күрүләре белән, мәдәни, бәдәви, вәхши дип аталалар. Шәһәрләр төзеп, иген игеп, хайван асрап, һөнәр сынәгать, сәүдә илә көн күрә торган кешеләргә “мәдәниләр” диләр. Бер урыннан икенче урынга күчеп, хайван асрап кына тереклек итә торган халыкларга “бәдәвиләр” диләр. Билгеле бер кәсеп вә эшләре булмаган, тау тишекләрендә, агач араларында яшәп, ни туры килсә шуны ашап, кыр хайваннары кебек яши торган кешеләргә “вәхшиләр” диләр.

## §25— Диннәр

Бөтен җир йөзендәге кешеләр нинди генә булса да бер динне тоталар. Дин буенча кешеләр насара (христиан), мөселман, мусави, будди, мәҗүси дип әйтеләләр.

Насаралар: Аллаһы Тәгаләне бар диеп, Гайсә гәләйһи сәләмгә ышанып, Инҗил белән гамәл итүче халыклардыр.

Мөселманнар: Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, Мөхәммәд галәйһи сәләмнең хак пәйгамбәр булуына ышанып, Коръән буенча гамәл итүчеләрдер.

Мусавилар: Аллаһы Тәгаләне бар диеп, Муса галәйһи сәләмгә инанып, Таурат буенча гамәл итүчеләрдер.

Буддилар: Будда исемле бер хакимнең васыятләре буенча гамәл итүче халыклардыр.

Мәҗүсиләр: үзләренең куллары белән ясаган потларына, елан, бака кебек төрле хәшәрәтләргә, күк күкрәү вә яшен кебек табигый нәрсәләргә гыйбәдәт итүче кешеләрдер.

## §26— Дәүләт вә падишаһлар

Мәдәни (цивилизованный) халыклар җәмгыять булып бер канунга буйсынып яшиләр. Бу җәмгыятьләрнең башында боларны идарә итүчеләр була. Алар җәмгыять эчендәге бөтен халыкның җаннарын, мал вә мөлекләрен саклыйлар. Усал адәмнәрдән юаш кешеләргә золым иттермиләр, гаеплеләргә җәза бирәләр. Менә бу кешеләргә "Падишаһлар" диләр. Канун вә низам астында бер падишаһның идарәсендә яши торган җәмгыятькә "дәүләт" падишаһлыгы диләр. Җир йөзендә дәүләтләр падишаһлар күптер.

## §27— Русия дәүләте

*(Җире 400,000 миллион мураббәг (квадрат), халкы 160 миллиондыр)*

Без туып яшәгән дәүләтне "Русия дәүләте" диләр. Русиянең җире дөньяның Яврупа вә Азия исемле бүлекләрендәдер. Яврупаның яртысы, Азиянең шәмәл шәркы (төньяк-көнчыгыш), шәмәл гарбе (төньяк-көнбатыш) тарафлары Русия дәүләте кулындадыр. Русиянең Яврупадагы җиренә "Яврупаи Русия", Азиядагы җиренә "Азияи Русия" диләр. Җиренең зурлыгы җиһәтеннән (ягыннан) бөтен дөньяда Англиядан кала Русия дәүләте икенче дәрәҗәдәдер.

**Чикләре:** Русиянең шәмәл тарафында Боз диңгезе, шәркында Олуг Мохит диңгезе (Тын океан), җәнүбендә Кытай, Әфганстан, Иран, Төркия дәүләтләре, Каспий вә Кара диңгезләр. Гареб ягында (көнбатыш) Румыния, Австрия, Алмания, Балтыйк диңгезе, Әсвәҗ (Швеция), Норвегия дәүләтләредер.

**Халкы:** Русиядә бер йөздән артыграк төрле кавемнәр, төрле милләтләр яшиләр. Әллә ничә төрле телләрдә сөйләүче, төрле ыругтан җыелган кавемнәр яшәсәләр дә, Русиянең бөтенлегенә һичбер зарар килми. Русиянең тугры кануны сәясәтендә бу кавемнәрнең һәркайсы бик рәхәт, тыныч гомер итәләр. Русиядә иң күп халык руслардыр. Болардан кала инарудислардыр[26]

---

[26] Инародцы – рустан башка халыклар.

Руслар: великий рус, малый рус, биларус исемнәре белән өчкә бүленәләр. Великий руслар Русиянең һәр җирендә, малый руслар яврупаи Русиянең гарбендә торалар.

Русларга башка халыклар ике җенескә: кавказ, монгол җенесләренә мәнсүбләрдер (карыйлардыр). Поляклар, литвалылар, немеслар, шведлар, грузиннар, әрмәннәр, яһүдиләр кавказ нәселеннәндер.

Руслар, грузиннар христианлыкның православный мәзһәбендәләр (агымындалар). Поляклар, литвалылар — католик. Немеслар, латышлар, финнарның беразы лютеран мәзхәбендәләрдер. Башкортлар, татарлар, тибтәрләр, мишәрләр, кыргыз, төркмәннәр, ногайлар, сартлар (үзбәкләр) ислам динендәләрдер.

Русия игенчелек мәмләкәтедер. Халкының күбрәге авылларда иген игеп, хайван асрап, умартачылык, аучылык, балыкчылык, мәгдән (тимер) казу, һөнәр, сәнәгатьчелек белән көн күрәләр.

**Мәгариф:** уку эшләре Русиядә бик ул кадәр югары булмаса да, соңгы елларда байтак алга китте. Урта хисап белән Русиядә укый яза белә торган кешеләр йөзгә 21дер. Йөздән 79 кеше укый да, яза да белми. Укыган кешеләр авылларга караганда шәһәрләрдә күбрәктер. Халыкның күпчелеге ибтидәи мәктәпләрдә (башлангыч) тәхсыл күрәләр. Русиядә ир вә кызларга махсус йөз меңнән артык ибтидәи мәктәп бар. Халыкның бик азы гына балаларын урта мәктәпләрдә укыталар, урта мәктәпләрнең саны да күп түгел. Анда укыту өчен зур мусарафәләр (маллар) тотырга кирәк, моңа һәркемнең хәле җитмидер.

## §28 — Русия дәүләтенең идарәсе

Русиянең бөтен идарәсе патша император хәзрәтләренең кулындадыр. Министрларны вә башка мәэмүрләрне (вазыйфалыларны) тәгйин итүче, Дума вә Государственный совет тарафыннан төзелгән кануннарны карап тәсдыйк итүче (раслаучы) улдыр. Яңа төзелә торган һәммә законнар, Государственный Дума белән Государственный Советта каралып бер карар бирелгәннән соң, патша хәзрәтләренең тәсдыйк итүенә тапшырыла. Ул әгәр дә законнарны мәмләкәт, халык өчен файдалы тапса — тәсдыйк итә. Государственный Думаның членнары бөтен халык тарафыннан

сайланалар. Совет членнарының бәгзеләре патша тарафыннан тәгйин ителәләр, вә кайсылары зур дворяннар тарафыннан сайланалар.

Төрле эшләрне карап идарә итер өчен төрле мәхкәмәләр бар:

Государственный Совет, Государственная Дума: боларда төрле кануннар төзеләдер. Правительствующий сенат бу мәэмүрләрнең кануннарны тугры йөрткәннәрен карап тәфтиш итеп торадыр. Синод: православныйларның көллиясе вә башка дини эшләрен карый, моның мәэмүрләре руханилардыр.

Дәхылия (эчке эшләр), сарай, мәгариф, бәхрия (диңгез), хәрбия (сугыш), юллар вә почта, телеграф, гаделия (гаделлек), мәлия (мал), җирләр министрлыклары исемнәрендә барысы ун министырлык бар. Бу министрлыкларның һәрберсенең башында министр тора. Патша вә бөтен югары мәхкәмәләр, министрлар башкалададыр. Русиянең берсе яңа, икенчесе иске башкаласы бар. Болар Петербург илә Мәскәү шәһәрләредер. Идарә итергә уңай булсын өчен бөтен Русияне берничә область вә губерналарга, губерна вә областьларны өязләргә, өязләрне станнарга, станнарны волостьларга бүләләр.


## §29— Яврупаи Русия

Яврупаи Русия киң түбәнсү тигезлекләрдәдер. Бу зур тигезлекләрнең уртасында Валдай Калкуы[27] исемендә шәмәлдән (төньяктан) җәнүбкә (көньякка) таба 1300 чакрым кадәр озынлыкта калку, түбән җирләр, сыртлар бар. Бу калкуның шәмәл тарафларына “Валдай таулары” диләр. Волга елгасының уң ягыннан, шәмәлдән җәнүбкә сузылган Волга сыртлары Валдай калкуларыннан киң ува белән аерылып торадыр. Валдай калкуы җәнүбкә таба сузылып барып, гаребтән шәрыкка озайган икенче бер калкуга тоташа. Бу калкуның гареб тарафына Әвһертин таулары, шәрык тарафына “Донецкий кряж” диләр. Яврупаи Русиянең тигезлекләренең шәрык тарафында Яврупаи Русияне Азияи Русиядән аера торган, шәмәлдән җәнүбкә Каспий диңгезенә таба озайган “Урал таулары” бар. Җәнүбендә Каспий диңгезе

[27] Валдайская возвышенность

белән Кара диңгезләр арасында “Кавказ таулары” , Кара диңгездә булган Кырым ярымутравында “Кырым таулары” бар.

Урал таулары нәкъ Боз диңгезе кырыеннан алып җәнүбкә (көньякка) Каспий диңгезенә таба 2 ½ мең чакрымга сузыладыр. Урал таулары Яврупаи Русияне себер ягыннан исә торган җилләрдән саклыйлар. Урал таулары җәнүбкә барган саен югарылана, биекләнә, тауның урта бүлегенә җиткәч тагын да түбәнәя. Җәнүб бүлеге берничә тармакларга аерыладыр. Урал


Благодать тавы


тауларының шәмәл вә урталарының бераз җире эре агачлы урманнар белән капланган. Җәнүб тарафлары үзенең матур манзаралары , төрле үсемлекләргә байлыгы белән Урал тавының башка якларыннан аермалыдыр. Урал тавының уртасында тимер, алтын, бакыр, көмеш, платина, тоз, мәрмәр кебек мәгдәннәр бик күптер. Тимернең иң күп чыга торган урыны “Благодать” исемле җирдәдер.


Дарьял чокыры

**Кавказ таулары:** Кара диңгез белән Каспий диңгезләре арасында, буе 1200, иңе 120 чакрым кадәр җирне каплаган

тезелгән таулардыр. Бу таулар сыртлары арасында вәдиләр, Дәрьял чокыры[28] кебек бик тирән чокырлар да бар. Кавказ тауларының Эльбрус, Дых тау, Казбек, Арарат кебек биеклекләре бишәр чакрымга җитә торган бик биек урыннары бар.

Кавказ таулары арасындагы кайсыбер вәдиләрдә һава җылы, хәтта



Эльбрус тавы

эссе булса да, тау башларында елның бер вакытында да бетми торган карлар, бозлар бар. Тау кабыргаларының югарырак урыннарында чыршы агачлары, түбәнрәк урыннары яфраклы агачлар белән капланмыштыр. Кавказ тауларының мәгъдәннәре әле дә бик нык тикшерелеп бетмәгән, монда табыла торган мәгъдәннәр: бакыр, көмеш, нефтьтер. Нефть – таудан чыга торган май. Безнең лампаларга салып яндыра торган керосин да шул нефтьтан алынадыр. Дөньяның һичбер урынында Кавказдагы кадәр күп микъдарда нефть чыга торган җир юктыр.

**Кырым таулары:** Кырым ярымутравының җәнүбеннән, диңгез яры буенча кояш чыгышы ягына таба сузылгандыр. Бу тауларның җәнүб тарафларындагы итәкләре бик текә булып диңгезгә төшәләр. Бу таулар Кырым таулары белән диңгез арасындагы җирне, шәмәл

---

[28] Дарьялское ущелье

(төньяк) ягыннан исә торган салкын җилләрдән саклыйлар, шунлыктан да монда кыш бөтенләй булмый. Бу урын безнең Русиянең һавасы иң яхшы булган җирдән санала. Монда Русиянең һәр тарафыннан күкрәк авырулы кешеләр дәвалану өчен киләләр.

**Финляндия таулары:** Яврупаи Русиянең Балтыйк диңгезе белән ак диңгез арасындагы калку биек җирләргә "Финляндия таулары" диләр.

Финляндия таулары башка таулар кебек тоташ тезмә түгел, бәлки аерым, гранитлы, бер берсеннән бик тирән күлләр белән аерылган, бик күп калку биеклекләрдән гыйбәрәттер. Тау башларыннан



Финляндиядә Иматра шарлавыгы


шаулап агып тора торган "шарлавыклар" бар.

Финляндия тауларының кайсылары шәп-шәрә таш, граниттан; бәгъзеләренең (урыны белән) өсләре эре ылыслы агачлар белән каплангандыр. Болардан тимер, бакыр, гранит, мәрмәр чыгадыр.

## §30— Яврупаи Русиядәге диңгезләр

Русиянең шәмәл тарафындагы боз диңгезе, ел буена диеп әйтерлек боз белән капланган була. Ялгыз җирләрдә генә Аврупаи Русиягә тоташкан читләре генә бераз боздан әрчелеп, өч айлар чамасы пароходлар йөрерлек була. Ул вакытта да бозлар тау тау булып йөзеп йөргәнгә күрә, пароходлар тыныч, куркынычсыз йөри алмыйлар.

Бу диңгездә кеше тормый торган Калгуеф, Вайгач, Яңа җир исемле утраулар бар. Бу атауларга җәйлектә судагыйрлар, балыкчылар, аучылар килеп балык тоталар, төрле диңгез хайваннарын аулыйлар, кош йоннары, кош мамыклары җыялар. Бу Боз диңгезеннән хасил булган диңгезгә Ак диңгез диләр.




Боз диңгезендә агып йөри торган боз таулары

**Балтыйк диңгезе:** Яврупаи Русиянең кояш баешы чигендәдер. Бу диңгездә Ботный, Фин, Рига исемле өч зур көрфәз (залив) бар. Рига көрфәзенең сәхиле (яры) түбәнсү тигезлек; Ботный, Фин көрфәзләренең ярлары текәдер. Кышлыкта кырыйлары туңадыр. Балтыйк диңгезе сай, түбәндә ташлы җирләре күп булганлыктан, пароходлар йөрер өчен бу диңгез бик ул кадәр уңайлы түгел. Төннәрдә, томанлы вакытларда ялгышып, пароходлар юлларыннан

чыгып, ташлы җирләргә барып кермәсеннәр өчен, диңгездәге атауларга вә сай урыннарга маяклар утыртканнар.

Русия Балтыйк диңгезе аркылы Англия, Франция, Америка вә башка дәүләтләр белән зур сәүдәләр итә. Бу диңгез аркылы Русиядән читкә бик күп мал чыгарыла, читтән бик күп мал китерелә. Шунлыктан Балтыйк диңгезе Русия өчен бик файдалы бер диңгездер.



Маяк алдында торган пароход

**Кара диңгез:** бу диңгез тирән, моның бер дә сай урыны юк. Сәүдә җиһәтеннән (ягыннан) безнең Русия өчен кара диңгез гаять мөһим урын тота. Кара диңгездә ел әйләнәсендә пароходлар йөрүдән туктамый. Моның шәмәл ягы гына ай ярым чамасы туңып тора. Яз вә көз көннәрендә Кара диңгездә куәтле дулкыннар була. Дулкын вакытында суы кара төстә күренә, моның Кара диңгез дип аталуы да шуның өчендер. Кара диңгезнең шәмәлендә, шушы диңгездән хасил булган Азак (Азов) диңгезе бар. Азак диңгезе сай булганлыктан, анда кечкенә пароходлар гына йөри. Бу диңгезләрдән балык бик күп аулана.

**Каспий диңгезе:** бу диңгез бөтен ягыннан коры җир белән чолганган, бер тарафыннан да диңгезгә кушылмый, шунлыктан диңгездән бигрәк зур күлгә ошый. Моның суы әче-тозлыдыр. Каспий диңгезенең тирәсе, түбән тигезлек кебек даладыр. Моның сәхилендә әһәмиятле лиманнар, портлар юк. Монда балык бик күп микъдарда аулана, һәр ел егерме миллион сумлык балык тотыла.

## §31 — Елгалар, күлләр

Безнең Русиядә елгалар бик күп. Шәмәл тарафындагы боз диңгезенә Печора, Шәмәли Двина (Төньяк Двина), Мезень, Онега елгалары коялар. Шәмәли Двина елгасы Сухона белән Буг исемле ике елганың кушылуыннан хасил буладыр. Боз диңгезенә коя торган елгалар арасында иң әһәмиятлесе Двина елгасыдыр. Моның суы күп, пароходлар йөрер өчен бик уңай, борынгы заманнан бирле Русиянең уртасыннан Ак диңгезгә чыгып йөри торган су юлыдыр. Онега елгасында пароходлар йөрмәсә дә, саллап агач агызалар. Печора елгасының суы күп, пароходлар йөртер өчен кулай бер елга булса да, тирәсендә халык бик әз булганга күрә әһәмияте аздыр.

Балтыйк диңгезенә Нива, Гарби Двина (Көнбатыш Двина), Неман, Висла елгалары коядыр. Гарби Двина елгасы, Валдай сыртларыннан чыгып, Рига көрфәзенә коя, монда киселтеләрнең күп булуы пароходларның йөрүенә уңайсыздыр. Неман елгасы Милски губернасындагы саздан чыгып, Балтыйк диңгезенә коядыр.

Кара вә Азак диңгезләренә Днепр, Днестр, Дон, Җәнүби Буг елгалары коялар. Днепр елгасының башы Валдай тауларыдыр. Моның башларында бик эре агачлы урманнар, агымында бик иген уңа торган басулар, мансыбына таба далалардыр. Днепр елгасында пароходлар йөрүен уңайсызлата торган киселтеләр, бусагалар[29] бар. Днепр елгасына уңнан Березина, Припять, сулдан Десна елгалары килеп кушылалар. Азак диңгезенә Дон елгасы коядыр. Дон елгасының уң ягыннан Донец елгасы килеп кушыладыр.

---


[29] Порог



Днепр елгасының киселтеләре

Каспий диңгезенә Волга, Урал елгалары коялар. Волга бөтен Яврупа кыйтгасендәге (өлешендәге) елгаларның иң озыныдыр. Яврупаи Русиянең уртасындагы Валдай тауларының итәгендәге Волгина Верховье исемле кечкенә бер рус авылы янындагы сазлыктагы чишмәдән чыгадыр. Волга елгасының уңыннан сулыннан барысы 200 кадәр елга килеп кушыладыр. Бу елгаларның зурраклары: Тверца, Малага, Шексна, Унжа, Кострома, Ветлуга, Кама. Уңнан Ока, Сура елгаларыдыр. Кама елгасына Ак Идел, Вятка Иделе (Нократ Иделе) килеп коядыр.


Кама елгасы кушылган җирдән башлап, Волга җәнүбкә таба борылып Каспий диңгезенә җиткәнче шул якка таба агадыр. Шексна тамагына кадәр Волга бик сай, агач салларыннан башка пароходлар йөрерлек түгел. Шексна тамагыннан башлап аның суы күбәя, киңәя; Ока, Кама елгалары кушылганнан соң тагын да күбрәк киңәеп, тирәнәеп китәдер. Кама елгасыннан түбән кайсыбер урыннарда аның киңлеге дүрт чакрым, тирәнлеге 15 саженьгә кадәр җитәдер.



**Волганың башы**

Волганың Ока тамагыннан башлап Түбәндәге Царицын шәһәренә кадәр уң ягы таулык, сул ягы тигезлек, болынлыктыр.

Волгада балык бик күптер. Волга үзенә кушылган елгалар белән Яврупаи Русиянең өчтән берен, Русиянең иң күп халыклы булган 22 губернасын сугара, Яврупаи Русиядәге халыкның өчтән бере Волга буенда торалар. Волга елгасы буенда барысы 39 шәһәр, меңнән артык зур вә кечкенә авыллар бар.



Нижний турысында Волга

Волгада һәр елны 100,000 дән артык олы вә кечкенә пароходлар иген, агач, мамык, чәй, кызыл мал кебек һәртөрле сәүдә малларын ташыйлар. Бик күп кеше җәй буена шушы пароходларда, баржаларда хезмәт итеп үзләрен вә гаиләләрен туйдыралар.

**Күлләр:** Яурупаи Русиядәге күлләрнең зурлары Ладога, Онега, Сайма, Ильмень, Чуд исемле күлләрдер. Бу күлләр Русия тигезлегенең шәмәл гарбе ягында (Петербург, Аланетский, Новгород, Псков губерналарындадыр). Ладога күле Яурупада иң зур күлдер. Бу күлләрнең суларының тәме төчедер. Җәнүб шәркы тарафында тозлы күлләр дә бар. Мондый тозлы күлләрнең иң зурлары: Эльтон, Баскунчак күлләредер. Баскунчак күленнән һәр елны 15 миллион кадәр пот тоз чыгаралар.

## §32 — Яврупаи Русиянең әкълиме (климаты)

Яврупаи Русиянең әкълиме һәр җирендә бертөрле түгел, шәмәл яклары (төньяк) боз диңгезләренә якын булганга күрә салкын, башка урыннарының әкълиме уртачадыр. Җәнүбкә (көнъякка) таба барган саен һава җылы була. (Архангельскида кыш 6 айга сузыла, Петербургта 5 ай, Әстерханда 3 ай, Кырымның җәнүбендә бөтенләй кыш булмый). Кояш баешы ягында Атлантик океаннан җылы, юеш җилләр исү сәбәпле, әкълим (климат) юеш һәм уртача була. Кояш чыгышы ягына киткән саен әкълиме үзгәрә. Кояш баешы ягына караганда, бу тарафта җәй бик эссе, кыш бик салкын була. Монда яңгыр еш яумый, Русиянең җәнүб шәркы тарафларында корылыклар бик еш буладыр.

Әстерханда кыш нык салкынлыгы, Бутни көрфәзенең (Ботнический залив) төн тарафындагы Торное шәһәрендәге кадәр буладыр. Җәйлектә шул ук Әстерханда эсселек, дөньяның эссе җирләрендәге кадәр була.

Әкълимнең үсемлек вә хайваннар дөньясына тәэсире бик зур. Шәмәл тарафлары бик калын кар, боз белән каплана, җәй көне карның өсте бераз гына эридер. Шул вакытта анда бераз мүк үсә, бу җирләргә “тундра” диләр. Тундралардан түбән җәнүбкә таба чәнечкеле чыбыклы кара калын урманнар сузылып китәдер. Бу урманнар кояш баешы ягына, Фин көрфәзенә (култыгына), кояш

чыгышы ягында Вятка[30] елгасына кадәр киләләр. Бу урманнарның җәнүбендә төрле катыш агачлы (Вятка тамагыннан Виленский губернасына кадәр) урманнар бардыр. Моннан җәнүбтәрәк яфраклы агачлар күренә, һәм бөтенләй урмансыз җирләр очрый.

Русиянең җәнүб тарафлары диңгез буйларына кадәр киң, тигез даладыр. Кырым, Кавказ тауларында тагын урманнар, агачлыклар күренәдер.

## §33 — Әкълим вә туфракның кешеләрнең тормыш, гадәт вә табигатьләренә тәэсире

Русиянең бөтен урынында туфрак, әкълим бертөрле түгелдер. Туфрак, әкълимнең төрлелеге өлкәнең үсемлекләренең, хайваннарының төрле төрле булуына сәбәптер. Шунлыктан Русиянең үсемлекләре, хайваннары урынына күрә аерыладыр. Моның өстенә Русиянең халыклары да бик күп төрле кавем кабиләләрдән җыелган. Туфрак, әкълим, халыкларда булган төрлелекләр халыкның сәүдәсен, кәсебен урынына, ягына күрә үзгәртә. Русиядәге шушы хосусыятне яхшырак тану өчен Яврупаи Русияне берничә табигый бүлекләргә, якларга аералар: зур күл буйлары, шәмәл ягы, Финляндия, Балтыйк диңгезе буе, Висла елгасы буе — кара туфраклы губерналар, дала яки җәнүби губерналар, Урал тавы буе — сәнәгатьле губерналар.

## §34 — Зур күлләр буе

**Петербург, Олонецкий, Новгород, Псков** губерналарына «күл буе яклары[31]» диләр. Бу якның туфрагы: калку җирләрендә комлык, вә төз тигез җирләре сазлыктыр. Петербург губернасыннан башка җирләрдә халык әз утырган.

**Халкы:** великий руслар белән руслашкан финнардыр.

Халыкның көн күрүе игенчелек белән. Арыш, солы, арпа, җитен чәчәләр. Җитен бигрәк тә Псков губернасында күп җитешәдер.

---

[30] Нократ Иделе
[31] Озёрный край



Зур күлләр буендагы бер күренеш

Монда җитешә торган иген күл буе халкына җитмидер, шуңа күрә авыллардан бик күп халык аш эзләп читкә китә, шәһәрләргә, төрле җирләргә тарала. Күлләрдән балык тоталар, шәмәл тарафындагы урманнардан агач кисәләр, ау аулыйлар. Бу якның иң зур сәүдә урыны Петербург шәһәредер.

**Мәшһүр шәһәрләр:** Петербург губернасында: Нева елгасының тамагында олуг Петр тарафыннан салынган Петербург шәһәре, Петербург безнең Русиянең пайтәхете, зур мәхкәмәләр мондадыр, бөтен Русиянең гыйлем мәгариф уртасыдыр, бик күп түбән, урта мәктәпләрдән башка дәрел фөнүн, берничә ирләргә вә хатыннарга махсус зур мәдрәсәләр бар. Русиянең бөтен әтрафыннан (якларыннан) ничә меңнәрчә егетләр вә кызлар гыйлем тәхсил итү өчен Петербургка киләләр. Петербургка өч су юлы, алты тимер юлы керәдер. Петербург су читендә дә бик зур урын тота. Моннан ерак түгел Кронштад каласы сугыш лиманыдыр. Царское село, Гатчина Петербург губернасында атаклы өяз шәһәрләредер.

Новгород губернасының баш шәһәре Новгородтыр. Русиянең бик борынгы шәһәредер.
Псков губернасының баш шәһәре Псковтыр. Җитен сәүдәсе белән мәшһүрдер.


Олонецки губернасының баш шәһәре Питразаводскидыр. Монда чуен заводы бар.



Зур күлләр буендагы бер авыл


## §35 — Шәмәл ягы[32]

Шәмәл тарафында Архангель, Вологда исемле ике губерна бар. Бу ике губернаның беренең зурлыгы, бөтен Яврупаи Русиянең 5 өлешеннән берсе чаклыдыр. Җиренә күрә халкы бик әз, сирәк утырган. Моның шәмәл тарафында зур калын урманнар бар. Туфрагы игенчелек өчен кулай түгел, әкълиме салкын. **Халкы:** лупарилар, зыряннар, самоедлар, руслар – поморлардыр.



Самоедлар

[32] Северный край




Поморларда балыкчылык эше

Бу губерналарда яшәүче халыкларның көн күрүләре балыкчылык, аучылык, агач кисү, хайван асраучылыктыр. Ак диңгез буенда торучы русларны “**помор**” диләр. Монда мөгезле хайваннардан бик сөтле халмагорский сыеры асрала.

Мәшһүр шәһәрләре: Архангель губернасында, агач сәүдәсе илә мәшһүр губернаның баш шәһәре Архангельдыр. Моннан башка мәмләкәтләргә агач, май, тире, мех китәдер.

Вологда губернасында губернаның башы Вологда шәһәредер.

## §36 — Финляндия

Ак диңгез белән Фин көрфәзе арасындагы Выборг, Ньюланд, Або-Бириненборг, Тавастгус, Вазас, Улеаборг, Куопиоск, Сант-Михель исемнәрендәге 8 губернага “Финляндия” диләр. Финляндиянең туфрагы бик бәрәкәтле түгел, җиренең өстенең күбрәк урыннары: ташлы таулар, бик күп күлләр, чәнечкеле агачлы урманнар белән капланганды. Финляндия салкын яклардан санала, шулай булса да, шәмәл ягындагы кебек үк салкын булмыйдыр.

Монда җитешә торган иген Финляндия халкына җитми. Бик күп микъдар читтән китереләдер.



**Халкы:** финнардыр. Аш сөючән, садә тормышны ярата торган. Салкынрак табигатьле халыклардыр. Финнарның һәркайсы ире хатыны укый-яза беләдер. Монда иген игүдән башка балыкчылык,




Финляндиядә урман

ташчылык, сәүдә белән дә көн күрәләр.

Хельсингфорс шәһәре Ньюланд губернасының һәм ботен Финляндиянең баш шәһәредер. Монда түбән урта мәктәпләрдән башка, дәрел фөнүн, ирләргә вә кызларга хас төрле гәли (югары) мәктәпләр дә бардыр.

## §37 — Балтыйк буе



Рига шәһәре

Курляндия, Лифландия, Эстляндия исемнәрендәге өч губернага “Балтыйк буе[33]” диләр. Бу якның диңгез буендагы җирләренең туфрагы комлы, иген игү өчен бөтенләй яраксыздыр. Башка урыннарда туфрак бик яхшы булмаса да, җирле халыкның яхшы эшләве сәбәпле, иген бик яхшы уңа. Бу губерналарда халык бик тыгыз утырган. Бер мүраббәгъ (квадрат) саженьгә 1,400 кеше туры килә.

**Халкы:** авылларда күбрәк латышлар, эстлардыр. Шәһәрләрдә торучыларның күбесе латышлар, эстлар, руслар, немеслардыр. Бу буйдагы җирнең күбрәк өлеше немес бароннары мөлкендәдер.

**Мәгариф:** монда Финляндиядәге кебек үк халыкта уку укыту эше бик югарыдыр.

**Мәшһүр шәһәрләре:** Курляндия губернасында Аа елгасы өстендә бу губернаның баш шәһәре Митава каласыдыр. Либава (Лиепая) лиманы бу губернададыр. Лафландия губернасында бу губернаның башы Гарби (Западная) Двина елгасы өстендәге Рига шәһәре. Рига 1201 нче елда салынган бик иске бер шәһәрдер.

---

33 Прибалтийский край

Сәүдә ягыннан Балтыйк диңгезе буенда Петербургтан кала икенче зур сәүдә лиманыдыр. Моның аркылы башка патшалыкларга агач, җитен, йомырка, иген китәдер.

Риганың үзендә вә тирәсендә пыяла, тимер, төрле машиналар ясала торган заводлар һәм кәгазь, пустау фабрикалары бик күп. Лафландия губернасындагы **Юрьев** каласы үзенең дәрел фөнүне белән данлыдыр.

Исландия губернасындагы Фин көрфәзендә **Ревель** шәһәре бар. Бу Исландия губернасының баш шәһәредер.

## §38— Висла буе

Висла вә аңа кушылган елгалар буендагы губерналарга “Висла буе”[34] диләр. Бу буйда Варшау, Калиш, Келец, Ломжин, Люблин, Петроков, Плоцки, Радомски, Сувалски, Седлец исемнәрендә барысы 10 губерна бардыр. Бу буйның шәмәл тарафлары түбәнсү, җәнүб яклары калкудыр.


**Туфрагы:** шәмәл тарафлары комлык сазлыктыр. Җәнүб тарафының туфрагы яхшы мүнбәттер (уңдырышлы). Монда бодай, тары вә башка игеннәр үсәдер.

**Әкълиме:** йомшак, кышын кар әз була, җәйдә яңгыр күп буладыр.

**Халкы:** балаклар, руслар, йәһүдиләр, литвалылар, немеслар. Монда җир бик кысык булганга күрә, халык бик тыгыз утыргандыр. Бу буйда фабрика, заводлар, тимер юллар бик күп. Сәүдә тиҗарат бик алда, халык гомумән байдыр.

**Мәшһүр шәһәрләре:** Варшау, Лодзь, Петрокоф, Сосновицы, Домброва, Ченстохов. Бу яктагы сәүдәнең күбрәге яһүдиләр кулындадыр.

[34] Привислянский край



Ревель губернасы



Поляк авылы

## §39 — Гарби губерналар

Ковена, Вилена, Гродна, Мински, Витебски, Могилев исемнәрендәге 6 губернага “Гарби губерналар”[35] дип әйтәләр.

Гарби губерналарның җире түбәнсүдер. Туфрагы комлык, сазламык, баткаклыктыр. Русиядә Пински атала торган зур сазлык мондадыр (Мински губернасында). Монда бик зур урманнар бар. Бу якның туфрагы бик бәрәкәтле түгелдер.

**Әкълиме:** уртача,юеш.

**Халкы:** белоруслар, литвалылар, яһүдиләр, балаклардыр. Литва татарлары исемле бераз мөселманнар да бардыр.

Бу тарафның халкы гомумтиле, фәкыйрь һәм надандыр.

**Мәшһүр шәһәрләре:** Гродна, Вильна, Витебски, Могилев, Мински, Ковена. Болар барсы да мондагы губерналарның баш шәһәрләредер. Бу якның иң яхшы зур шәһәре Вильнадыр.

---

35 Западный край

## §40— Урта губерналар

Тверь, Ярославль, Кострома, Нижний-Новгород, Мәскәү, Владимир, Тула, Калуга, Рязань, Смоленский исемнәрендәге губерналарга “ Урта губерналар[36]” яки “Сәнәгатьле губерналар” дип әйтәләр.

**Туфрак:** бу губерналарның туфрагы күл буе якларының туфрагы сымак. Үстерү хасияте аздыр. Бары Нижний-Новгород губернасының җәнүб тарафында гына бераз юкарак кара балчыклы җирләр бардыр.

**Әкълиме:** бик тиз алмашучан (мутәбәддил). Бу губерналарда кыш озын һәм яхшы ук салкын булып, җәй эссе була. Кар 5 ай кадәр тора, яз соң һәм бик кинәт була. Җәйлектә көндезен кызу, кичен салкын була. Монда әкълим гел алмашынып кына тора.

**Халкы:** бу губерналардагы халыкның күбесе великий руслардыр.



Великий рус өе

Нижний-Новгород губернасында әзрәк татарлар (мөселманнар), мокшалар бар.

[36] Центральное промышленное пространство


Бу губерналардагы җирнең яртысы сөрә торган игенлек басуыдыр. Шунлыктан иген игү монда беренче урынны ала. Монда арыш, солы, бәрәңге чәчәләр.

Халкы бик күп һәм тыгыз утырганга күрә, монда чәчелгән ашлык бу губерна халкының үзенә җитми. Русиянең башка губерналарыннан китерәләр.

**Бакчачылык:** Ярославль губернасында, Ростов өязендәге халыклар иген игүдән башка бакчачылык белән дә кәсеп итәләр.

**Хайван асраучылык:** бу губерналарда хайван асраучылык кәсебе юк дип әйтерлек түбәндер. Йортка кирәкле берничә хайваннан артык хайванны монда асрамыйлар. Зур шәһәрләргә сугым өчен көн ягындагы губерналардан килә. Монда игенчелек эше бик ул кадәр шәп булмаганга күрә, бөтен халык үзләренең тормышларын икенче яктан юнәйтү юлын караганнар. Улда завод, фабрикаларда эшләү, һөнәр, сәнәгать, сәүдә һәм башкача читкә китеп хезмәт итүдер.


**Фабрика вә заводчылык:** Русиядә фабрика, заводның иң күп урыныдыр. Монда барысы 4,000 кадәр фабрика бардыр.



Фабриканың тыштан күренеше

**Һөнәр, сәнәгать:** бу губерналарда бик күп кеше үз өйләрендә төрле нәрсәләр эшлиләр. Мәсәлән: киндер тукыйлар, пычак, балта, йозак, самовар ясыйлар, карзинка үрәләр. Урындык, өстәл, шкаф, камод кебек җиһазлар эшлиләр. Балалар уенчыклары кебек нәрсәләр дә ясыйлар. Һәр елны әллә никадәр аяк киеме хәзерлиләр.

**Читкә барып эшләү** (отхожий промысел)**:** халыкның бик күбесе Петербургка вә башка зур шәһәрләргә эшче булып төрле заводларга, фабрикаларга, төрле сәнәгать урыннарына керәләр, бик күбесе пароход йөри торган зур елгалар буенда салчы, матрос булып хезмәт итәләр. Калуга, Кострома губернасыннан бик күп кеше төрле шәһәрләрдә ташчылар, морҗа чыгаручылар, өй эшкәтүрләүчеләр, буяучылар, балта осталарыдыр.



Фабриканың эчтән күренеше

Тверь губернасыннан кучер вә балта осталары күптер, Ярославльдән сәүдәгәрләр, бакчачылар, Владимир губернасыннан тегүчеләр бик күп була. Нижний-Новгород халкының күбесе параход пристаньнәрендә, пароходларда хезмәт итәләр. Кайсыбер авылларның ирләре кыш буена читтә эшләп, җәй иген эшләре өчен өйгә кайталар.

Кайсыбер урыннарда һәммә сау-сәламәт ир кешеләр бөтен ел әйләнәсенә өйләреннән китеп читтә эшлиләр, өйләрендә бөтен кыр басу эшләрен хатыннары эшли, сука сөрәләр, көлтә китерәләр, хәттә сотский, старосталык хезмәтен дә эшлиләр[37] (Безнең Уфа, Казан губерналарындагы авылларның мөселман хатыннарын да арттырганнар икән!)

**Мәшһүр шәһәрләре:** Мәскәү губернасында Мәскәү шәһәредер.

Мәскәү Русиянең борынгы бай тәхетедер, иң зур сәүдә урыныдыр. Гыйлем, мәгариф урыннарының күплеге белән дә данлыдыр. Дәрел фөнүн вә берничә башка зур мәдрәсәләре бардыр.Монда сәүдә итеп вә төрле хезмәтләрдә торучы бераз мөселманнар да бар.

[37] Краткий курс географии, А. Бернашевский

Мөселманнарның гыйбәдәтханәләре, имамнары барлыгы мәгълүм булса да, бер рәтле ибтидәи (башлангыч) мәктәпләре барлыгы билгеле түгелдер. Сәүдәгәрләрнең күбрәге иске-москы нәрсәләр белән сату итүче мишәрләрдер. Нижний-Новгород губернасында Нижний-Новгород шәһәредер. Монда һәр ел август аенда ярминкә буладыр. Нижнийда бераз мөселманнар бар, мөселманнарның гыйбәдәтханәләре, ибтидәи мәктәпләре бардыр. Тверь, Ярославль, Калуга, Рыбински, Кострома, Владимир, Тула, Смоленски зур сәүдә шәһәрләредер.

## §41 — Ашлык уңа торган кара туфраклы як

Киев, Чернигов, Виленский, Подольски, Полтава, Харьков, Орлов, Тамбов, Курский, Воронеж, Пенза, Симбирь, Самара, Саратов губерналарына "Кара туфраклы, ашлык уңа торган як"[38] диләр.

**Туфрак:** бу якның туфрагы бик бәрәкәтле кара балчыктыр. Бу якта кара туфракның калынлыгы 3 аршин тирәнлегенә кадәр җитә.

**Әкълиме:** кояш баешы тарафында әкълиме йомшак вә уртача. Яңгыр һәм кар җитәрлек кадәр ява. Кояш чыгышына таба барган саен әкълиме корый. Кыш салкын, җәй эссе, шунлыктан кояш чыгышы якларында кайсы елларда игеннәр корып ачлык килгәлидер.



Малорос өе

[38] Черноземное пространство

**Халкы:** кояш баешы якларында малорослар, кояш чыгышы тарафында великий руслардыр. Болардан башка кояш баешы тарафында йәһүдиләр, балаклар торалар. Кояш чыгышы тарафында татарлар, Сембер, Саратов, Тамбов, Пенза, Самара губерналарында мишәрләр, чувашлар, мокшалар, немеслар бар.

Малорослар бик эш сөючән, юаш табигатьле халыктыр. Алар Киев, Чернигов, Подольски, Харьков, Полтава губерналарында торалар. Шуның өчен бу губерналарны “Малороссия” дип тә әйтәләр.Болар бик тыгыз утырганнар. Боларның иң сөекле эшләре игенчелектер. Бакчачылык, Урманчылык кәсебе дә бардыр. Боларның өйләре яшеллекләр арасында, бакча эчендә күмелеп утыра.

Алма, кара җимеш, кара җиләк үсәдер. Кавын, карбызны басуларга чәчәләр, мондый кавын, карбыз басуларына “бахча” диләр. Кара туфраклы губерналарга “Русиянең келәте” диләр. Монда арыш, бодай, арпа, солы, тары, кара бодай, сус, тәмәке (Чернигов губернасында), чөгендер чәчәләр.

**Хайван асраучылык:** Урта губерналарга якын җирләрдән башка урыннарда хайван асрау да алда. Бу якта җигеп сабан сөрә торган зур үгезләр, сугым өчен итле хайваннар бик күп үрчидер.



Малороссиядә җир сөрү


**Завод вә фабрикачылык:** зур зур паровой тегермәннәр, чөгендер, шикәр, тире заводлары күптер. Фабрикалар бары төн якларында гына булып бик әздер.

**Сәүдә:** бу якның сәүдәсе ярминкәләрдәдер. Бу якта хосусан Малороссиядә ярминкәләр бик күп була. Русиянең урта губерналарыннан фабрикачылар, үзләренең товарларын алып килеп, мондагы халыкка саталар, җирле халыктан йон, тире, мөгезле хайваннар, атлар вә башка нәрсәләр алалар. Бу якның иң зур сәүдәсе иген беләндер.

**Мәшһүр шәһәрләре:** Подольский губернасындагы Каменец-Подольский шәһәре губернаның башкаласыдыр. Волынский губернасындагы Житомир каласы бу губернаның баш шәһәредер, һәм иген сәүдәсе белән атаклы. Киев губернасында Киев шәһәредер, бу шәһәр Русиянең бик борынгы шәһәрләреннән санала, монда дәрел фөнүн вә башка зур мәктәпләр бар. Чернигов, Полтава, Харьков, Курски, Орел, Воронеж, Тамбов, Пенза, Симбирь, Самара, Саратов губерна шәһәрләредер. Бу шәһәрләрнең һәркайсы зур сәүдә урыннарыдыр.

Харьков вә Саратов шәһәрләрендә дәрел фөнүннәр бар. Харьковта сәүдә итеп, төрле кара эш эшләп торучы мөселманнар да бар.

Тамбов, Пенза, Симбирь, Самара, Саратов губерналарында байтак




Орлов губернасында бер авыл

мөселман бар[39].

Пенза шәһәрендә торучы халык мөселман булып, мәчетләре имамнары барлыгы мәглүм булса да, бер рәтле ирләргә вә кызларга махсус ибтидәи мәктәпләре барлыгы мәгълүм түгелдер.

## §42— Дала яклары

Кара туфраклы, ашлык уңа торган якның көньягында, Азов, Кара, Каспий диңгезләренең төньягындагы губерналарга “Дала ягы, степьтәге губерналар[40]” диеп әйтәләр. Бессарабия, Херсон, Екатеринослав, Таврический, Ставорополь, Астерхан, Донская область губерналары шушы далададыр.



Кара диңгез буендагы дала

Бу якның күренеше тигез, көн ягына таба түбәнсү, Каспий диңгезе тирәләрендәге даланың өсте диңез өстеннән түбәнрәктер. Тигез, киң

---

39 Мөселманнар Пенза губернасында 64,000; Самарада 308,000; Саратов 116,000; Симбирьдә 153,000; Тамбовта 18,000

40 Степное пространство

далада тирән чокырлар, күлләр очрый. Яз көннәрендә аларның эчләре сулар белән тулып, иңкү якка таба агалар.


**Туфрак:** көньягы тарафларының туфрагы кара, ялгыз елга вә диңгез буйларының гына туфрагы комлыдыр. Кояш чыгышы тарафларының туфрагы бөтенләй комлыдыр.

**Әкълиме:** җылы вә коры. Җәй озын, эссе, коры. Кыш салкын, кар әз була. Монда иң әйбәт вакыт яз вә көздер. Кояш чыгышы ягына барган саен яңгыр кар әз, әкълиме бик тиз алмашынучан.

Кара диңгез буйларында бөтен дала кеше биеклегендә үлән белән каплана. Хәзерге көндә ул якларның бик күп җире сөрә торган җирдер.

Каспий диңгезе буендагы далалар үләнгә бик бай түгел. Монда үлән каты, өем-өем булып үсәдер.

**Халкы:** бу якның халкы бик күп төрле кавемнәрдән җыелган булса да, күбрәге руслардыр.



Каспий диңгезе буендагы дала

Кояш баешы ягында малорослар, кояш чыгышы тарафында великий руслар, дон казакларыдыр. Бессарабия губернасында румыннар, Кырым ярымутравында татар (мөселманнар). Каспий даласында кыргыз (мөселманнар), калмыклар. Бу якның төрле

җирләрендә торучы немеслар, болгарлар, серблар, шәһәрләрдә әрмәннәр, яһүдиләр бар.

Дала губерналары Русиянең иң бай губерналарыннан санала.

Монда игенчелек кәсебе бик югары урын тота. Кара туфраклы губерналарга караганда иген монда артыграк уңа. Күбрәк бодай чәчәләр, арыш арпа да чәчәләр. Бессарабиядә кукуруз, сус, тәмәке җитештерәләр. Кырымда виноград бакчалары күптер.

**Бакчачылык:** бу якның көньягы бүлегендә, хосусан Кырымда, бакча эше бик зурдыр. Монда алма, дулә, кара җимеш, кара җиләк, чиядән башка эссе якларда үсә торган абрикос, миндаль кебек бик күп төрле җимешләр үстерәләр.

**Хайван асраучылык:** бу якның иң зур кәсебедер. Каспий диңгезе буенда яшәүче кыргыз вә калмыкларның бар көн күрүе хайван асрау беләндер. Иң күп асралына торган хайван сарык, куй, ат, сыердыр. Сарыклар, атлар, сыерлар зур-зур көтү булып йөриләр.

**Балыкчылык:** диңгезгә коя торган зур елгалардан, елгаларның тамакларыннан, Каспий диңгезеннән бик күп балык алынадыр.

**Мәгәдин (**ископаемые): бу якта иң кирәкле мәгдәннәрдән тимер, җир күмере, тоз, тере көмеш чыгадыр. (Тимер Херсон, Екатеринослав губерналарында чыга.)

**Сәүдә:** диңгез буйларында лиманнардагы шәһәрләрдә сәүдә бик зурдыр. Бу шәһәрләр аркылы икенче патшалыкларга бик күп иген китәдер. Атаклы шәһәрләр: Бессарабия губернасында Кишинев каласы губернаның баш шәһәредер.

Херсон губернасында Херсон губернаның башкаласыдыр. Елизаветгород, Николаев, Одесса шәһәрләре бик зур сәүдә урыннарыдыр. Одессада дәрел фөнүн вә башка уку урыннары бик күптер. Екатеринослав губернасында Екатеринослав губернаның башкаласыдыр, фабрика заводлары илә данлыдыр.

Таврический губернасында Симферополь губернаның башкаласыдыр. Севастополь, Кәфә, Ялта, Бакча Сарай шәһәрләре бардыр.

Бакча Сарай шәһәре иске Кырым ханнарының бай тәхете булмыштыр. Бүгенге көндә монда иң күп халык мөселманнардыр. Мөселманнарның мәчетләре, мәктәп мәдрәсәләре бардыр. Бөтен Кырым мөселманнарының дини рухани эшләрен карый торган духовный правление исемендә бер мәхкәмә бар.

Әстерхан губернасында, Волганың Каспий диңгезенә койган җирендә Әстерхан шәһәредер. Искедә ногай, татар ханнарының бай тәхете булган. Бү көндә дә монда мөселманнар бар. Мөселманнарның берничә зур-зур мәчетләре, берәр бераз тәртиплерәк ибтидәи мәктәпләре бардыр. Моның сәүдәсе балыктыр.

Донская область: монда Дон казаклары тора. Боларның үзләренә махсус идәрәләре бар. Новочеркесский, Таганрог, Ростов Дон моның атаклы шәһәрләреннәндер.



Волгада балык тарту



Кырым ярымутравының көньягында диңгез яры

## §43— Урал буе

Вятка, Казан, Пермь, Уфа, Оренбург исемнәрендәге 5 губернага “Урал буе”[41] диләр. Урал буеның кояш чыгышы тарафлары – таулык, кояш баешы тарафлары – тигезлектер. Кояш баешы тарафының туфрагы кара балчыклы булып иген яхшы буладыр. Кояш чыгышы ягының туфрагы комлы, ташлыдыр. Урал буе губерналарында рус, башкорт, татар, тибтәр, мишәр, чуваш, чирмеш, ар, пермяк, вагол, кыргыз, калмык кебек бик күп төрле халыклар торалар. Урал буенда барысы 9 миллион кадәр кеше яши. Иң күп халык великий руслардыр, аннан кала башкортлар (ялгыз Уфа губернасының яртысыннан күбрәк халкы башкортлардыр).

**Тормышлары:** бу як халкының иң зур кәсепләре иген игүдер. Монда арыш, арпа, солы, кара бодай, бодай, тары, җитен, киндер чәчәләр. Көньягы тарафларында, Уфа, Оренбург губерналарында ат, сыер, сарык, куй, кәҗә кебек хайваннар асрыйлар. Уфа, Вятка,

[41] Приуральский край

Пермь губерналарында умартачылык эше дә бик яхшыдыр. Урал буендагы халыкларның иң зур кәсепләре – Урал тауларыннан мәгдән чыгарудыр. Урал тавында алтын, тимер, көмеш, бакыр, платина һәм бик күп микъдарда таш тозы чыгадыр. Урал буе үзенең төрле мәгдәннәргә байлыгы белән бөтен Русиядә беренчедер. Тимер сәүдәсе Урал тавындагы кадәр дөньяның бер җирендә юктыр.



Урал тавы


Тимерне бик зур пичләрдә эретеп чуен, тимер, сталь кебек әллә ничә төрлегә аералар. Тимер рудасы эретә торган пичләр Урал тавы буенда бик күптер. Моңа "доменный пич" диләр. Урал буеның урманлы җирләрендә аучылык, урман кисү белән дә бик күп кеше көн итәдер. Кама, Ока, Иделдән саллар агызалар, дегет, смола ясыйлар.

**Атаклы шәһәрләр:** Вятка губернасында Вятка каласы. Бу губернаның баш шәһәре булып, икмәк сәүдәсе белән данлыдыр. Вятка каласының үзендә һәм губернасында байтак мөселманнар да бар. Малмыж, Сарапул өяз калалары.

Казан губернасында Казанка елгасының Волгага кушылган җиреннән 6 чакрым җирдә, Волганың сул ягында сабын, пыяла, күн, шәм заводлары илә атаклы Казан шәһәредер. Казанда бик күп

урта мәктәпләрдән башка, дәрел фөнүн, терлек (хайван) табиплары җитештерә торган институт, кызларга махсус зур мәдрәсә бар.

Казан шәһәре борынгы татар ханнарының бай тәхете булмыштыр. Бу көндә ханнардан калган Сөембикә манарасы (Хан мәчете) атлы бер манара бар.



Доменный пич

Казанда мөселманнар да бик күп булып, аларның 17 сан гүзәл фасадта салынган мәчетләре, ул мәчетләр хозурында мәктәп вә мәдрәсәләре бар. Русиянең төрле тарафларында яшәүче мөселманнардан бик күп яшь егетләр гүлүм шәргыя (шәригать белеме) тәхсил итәр өчен киләләр.

**Мәдрәсә Мөхәммәдия, мәдрәсә Касыймия** Казан мәдрәсәләре арасында иң алдынгылары саналалар.

**Пермь** губернасында, Кама елгасының өстендә губернаның башкаласы Пермь шәһәредер. Екатеринбург, Эрбет шәһәрләре зур сәүдә урыннарыдыр.

**Уфа** губернасында Уфа губернаның башкаласыдыр. Уфа губернасында Златоуст, Эстәрлетамак, Бәләбәй, Бирски, Минзәлә өяз калаларыннандыр. Уфада Урта Русия мөселманнарының дини вә рухани эшләрен карый торган духовный собрание исемендә бер мәхкәмә бар. Уфа шәһәрендә мөселманнар байтак булып,

мөселманнарның берничә мәчетләре, ул мәчетләр хозурында мәктәп вә мәдрәсәләре бар.

**Оренбург** губернасында Оренбург шәһәре губернаның башкаласыдыр. Сибирия белән Яврупаи Русия арасында зур сәүдә урыныдыр. Монда мөселманнар да күп булып, мәчетләре, мәктәп вә мәдрәсәләре бар. Мәдрәсәләре арасында “мәдрәсә Хөсәения” иң тәртиплесе булып, монда гүлүм диния белән берә-бер әзрәк яңа гыйлемнәр һәм мәмләкәт теле русча да укыталардыр.

## §44— Азияи Русия

*(җире 300 мең мүраббәгъ (квадрат) миль, халкы 27 миллион)*

Азияи Русия: Кавказ, Себер, Туркестан исемнәре белән өчкә бүленә.

### Кавказ

*(Җире 8,500 мүраббәгъ (квадрат) миль, халкы 11 миллион)*

Кара диңгез белән Каспий диңгезләре арасындагы җирләр “Кавказ” дип аталадыр. Чиге: төньягында Яврупаи Русия, көньягында Иран, Төркия дәүләтләредер. Табигый хәлләре һәм җиренең өстенә күрә, Төньяк Кавказ[42], Дагестан (Олуг Кавказ)[43], Көньяк Кавказ (кечкенә Кавказ)[44] исемнәре белән өчкә бүленәдер. Төньяк Кавказның төньяклары тигез булып, көньягына таба барган саен калкулана, югарылана бара. Тауларыннан олы, кечкенә берничә елга агып төшәдер. Терек, Кубань, Кума мондагы иң зур елгалардыр.

Кубань, Терек елгаларының аргы яклары, (көньягына таба тарафлары) бик әйбәт урманнар белән капланмыштыр. Төньяк Кавказның кояш баешы тарафы Русиянең иң иген уңа торган җирләренең берседер. Туфрагы кара, әкълиме җылы, май, июнь айларында була торган яңгырларның күплеге игенне бик уңдырадыр.

**Дагестан**: Кара диңгездән Каспий диңгезләренә кадәр. Барысы 1000 чакрым чамасы таулык җирдән гыйбәрәттер. Иң биек урыны,

[42] Северный Кавказ
[43] Большой Кавказ
[44] Малый Кавказ

Терек, Кубань елгалары арасындагы Эльбрус, (биеклеге 5 1/3 чакрым) Дыхтау, Казбек вә башка таулардыр. Әкълиме тауларның биеклекләренә күрәдер, төрле үсемлекләр дә шуңа карап йөридер. Тауның итәкләрендә 5,000 футка кадәр, куе яфраклы агачлар, аннан югарырак 8,000 футка кадәр, ылыслы агачлар, аннан югарырак тау башларында үсә торган үләннәр, аннан да өстәрәк бер дә бетми торган карлар, бозлар белән каплангандыр.

**Кечкенә Кавказ**: Риони, Кура елгаларының буена, Дагестанның көньягы тарафына "Кечкенә Кавказ" диләр. Кечкенә Кавказ тау араларындагы вәдиләрдән, сыртлардан тезелгән таулардан гыйбәрәттер. Моның иң биек урыны Арарат тавыдыр. Риони елгасының буе, Кара диңгез яры буйлары, яңгырларның күплеге сәбәпле әкълиме юеш. Монда кышны, суыклыкны бөтенләй белмиләр дә. Һавасының җылылыгы, юешлеге сәбәпле бу җир дөньяның иң гүзәл, матур бакчасыдыр. Кура елгасының буе киресенчә бик көйдерә торган кызудыр.



Кавказдагы халыклар

**Халкы:** Кавказда бик күп милләткә караган, әллә ничә төрле телдә сөйләшә торган халыклар яшиләр. Төньяк Кавказдагы халыкларның күбрәге руслардыр. Шәмәл шәркы якларында бераз ногайлар белән калмыклар бар.

Кавказ тауларының ике як кабыргаларында таулылар, черкеслар, чеченнар, лезгиннар вә башкалар торалар.



Черкес авылы

Кечкенә Кавказның кояш баешы якларында грузиннар, гурилар, имеретиннар, мегреллар, кояш чыгышы тарфында татарлар, әрмәннәр (Кура белән Аракс елгалары арасында) торалар.

**Тормышлары**: игенчелек, бакчачылык, хайван асраучылык, ефәкчелек, һөнәр-сәнәгать беләндер.

**Игенчелек**: Кавказда игенчелек эше яхшыдыр. Көньяк Кавказда, яңгыр әз ява торган урыннарда, иген басуларын казылган каналлар ярдәме илә сугаралар. Күбрәк бодай, арыш, арпа, җитен, дөге, тары, кукуруз игәләр.

**Бакчачылык**: Кавказда виноград бик күп үсәдер. Кавказны “Виноградның ватаны” диләр. Виноград басуларда үсәдер. Терек елгасы буендагы халыкларда виноград эше бик алдадыр. Монда мамык, тәмәке, чәй агачлары үсәдер. Көньяк Кавказда шәфталу, апельсин, лимон, банан, ананас вә башка җылы җирләрдә житешә торган җимешләр дә үсәдер.

**Хайван асраучылык:** Кавказдагы халыкларның һәммәсенең хайван асраучылык кәсебе бар. Калмыклар белән ногайларның иң беренче

кәсепләре хайван асраудыр. Күбрәк асралына торган хайван – сарык. Сарык ите Дагстан халкының иң сөйгән ашыдыр. Сөт, катык, май вә җир сукалау өчен мөгезле хайваннар, атланып йөрү өчен ат асрыйлар.

**Ефәкчелек:** Кавказда ефәкчелек кәсебе дә бар.

**Мәгәдин** (ископаемые.): Кавказда мәгдән байлыкларыннан иң беренчесе нефтьтер.

**Фабрика вә завод:** Кавказдагы заводларның күбрәге нефть заводларыдыр. Нефть заводының иң күп җире Баку шәһәредер.


**Һөнәр сәнәгать:** мылтык, хәнҗәр һәм төрле көмеш нәрсәләр ясыйлар, паласлар, яулыклар тукыйлар, күн илиләр.

Кавказ 6 губернага, 4 областькә бүленә. Губерналары: Ставрополь, Кутаис, Кара диңгез, Ариван, Елизаветополь, Баку. Областьләре: Кубань, Терек, Дагестан, Карс.

**Атаклы шәһәрләре:** Батум, Тифлис, Баку, Ставорополь, Екатеринодар, Новороссийский, Владикавказ, Тимер хан шура,



Нефть чыгару.



Баку шәһәре

## §45— Сибирия

*(Җире 227 мең мураббәгъ миль, халкы 7 миллион)*

Азиянең төньяк бүлегенә “Сибирия” диләр. Моның төньягында Боз диңгезе, кояш баешында Олугъ Мохит диңгезе, көньягында Кытай падишаһлыгы, Төркестан виләятләре, кояш баешы ягында Урал таулары вә Яурупаи Русиядер.

Себернең төньягы, кояш баешы тарафлары бик киң тигезлектән гыйбәрәттер. Кояш чыгышы ягы тәбәнәгерәк таулар вә тезелгән таулар белән капланмыштыр.

**Туфрак**: Себернең туфрагы бар җирендә дә бертөрле түгел: көньяк тарафларының туфрагы кара, төньяк тарафларының туфрагы сазланмык. Көньяк тарафларында иген бик яхшы җитешәдер.

**Халкы**: Себердә җирнең зурлыгына караганда халкы бик әздер. Себердә руслар, якутлар, тунгуслар, остяклар, бурятлар, камчадаллар, калмыклар, гиляклар, чукчалар, самоедлар, кыргызлар торалар.

**Тормышлары**: игенчелек, балыкчылык, аучылык, хайван асрау һәм мәгъдәнчелек беләндер. Игенчелек белән яши торган халыклар ялгыз руслар гынадыр. Җирнең күп урыны иген игү өчен бик улкадәр яраклы булмаса да, кайсыбер урыннарында иген бик яхшы буладыр. Мәсәлән Обь, Иртыш елгаларының арасы “Себернең келәте” дип атала. Бодай, арыш, кара бодай, арпа, солы, тары чәчәләр, җеп, аркан өчен сүс, җитен җитештерәләр.

**Хайван асраучылык** белән күчмә халыклар гына түгел, руслар да күп шөгыльләнәләр. Көтү-көтү сарык, куйлар, ит-май өчен сыерлар, вә бик күп елкы асрыйлар. Себердән Яврупаи Русиягә, чит падишаһлыкларга ел саен бик күп микъдарда май китәдер. Тундраларда болан, шәмәл шәркы тарафларында җигеп йөрү өчен эт асрыйлар.

Чукчалар, гиляклар, камчадаллар балыкчылык белән көн күрәләр.

**Аучылык:** Себердә иң зур кәсеп аучылыктыр. Себернең урманнары тиресе кыйммәтле җәнлекләргә бик байдыр. Кара төлке, соболь, Камчатка, Беринг диңгезләрендәге утрауларда мехы кыйммәтле диңгез мәчесе ауланадыр.

**Мәгдәннәр:** Себернең бөтен урыны өйрәнелеп бетмәгән булса да, Себер мәгдәнгә бик байдыр. Тоз, алтын, көмеш, җир күмере, тимер рудасы, нефть табыладыр.




Эт җигеп йөрү

**Фабрика:** фабрика вә заводчылык эше Себердә бик түбәндер. Эшләнгән нәрсәләрнең бөтенесе Яврупаи Русиядән китерелә. Фабрика малларына каршы Себердән Яврупаи Русиягә җәнлек тиресе, май, бодай чыгарыла. Себердән икмәк, май вә башка нәрсәләрнең читкә чыгуы, Себер тимер юлы салынганнан соң бигрәк тә артты. Себер тимер юлы Себеренең сәүдә ягыннан алга китүенә бик зур тәэсир итте.

Себер, Тобольский, Томский, Енисейский, Иркутский исемнәрендә 4 губернага; Якутский, Забайкальский, Амурский, Сахалин утраулары белән бергә Камчатский белән 5 областькә бүленәдер.

**Атаклы шәһәрләре:** Тобольск губернасында Тоболь суы белән Иртыш елгасының кушылган җирендә Тобольский шәһәре губернаның башкаласыдыр. Тура елгасында Төмән каласы тире, шәм, сабын, май заводлары белән данлыдыр.

Томский губернасында: Томь елгасы өстендә кояш баешы тарафында, Себернең иң яхшы калаларыннан, губернаның башкаласы Томски. Дәрел фөнүн, паравой тегерменнәре, тире заводлары белән данлыдыр. Барнаул — Алтай тавындагы заводларның идәрәсе мондадыр, һәм икмәк сәүдәсе белән дә данлыдыр. Томскида мөселманнар да байтак булып, мәчет һәм мәктәп бар.



Себердә алтын табу

Енисей губернасында: Красноярский губернаның башкаласыдыр, монда икмәк сәүдәсе зурдыр.

Иркутский губернасында: Ангара елгасы өстендә Иркутск каласы, кояш чыгышы ягындагы Себернең баш шәһәре, генерал губернаторның тора торган урыны. Иркутский Себернең зур, иң төз вә матур, зур сәүдәле калаларыннандыр.

Якутский губернасында: Лена елгасы өстендә Якутски шәһәре губернаның башкаласы. Сәүдәсе җәнлек тиресе белән.

Забайкальский областендә: Чита, Нерчински, Кяхта калалары. Чита областьнең башкаласы. Нерчински тирәсендә көмеш рудасы чыга торган җирләр бар. Кяхта чәй сәүдәсе белән данлыдыр.



Гиляклар

Амурский областендә: Амур елгасы буенда Благовещенский область мәркәзедер.

Приамурский областендә: Уссури елгасының Амурга кушылган урынында Хабаровск областьнең башкаласыдыр. Владивосток каласы Япония диңгезендә сугыш лиманыдыр. Камчатский областендә: Петропавловский каласы сугыш лиманыдыр. Идәрә ителү ягыннан, Сахалин утравының Русия кулындагы бүлеге Камчатский областенә карыйдыр.





Сахалинда җир күмере шахтасы

## §46 — Төркестан

*(Җире 60 мең мураббәгъ, халкы 9 миллиондыр)*

Кояш баешы Себернең көньягында, Каспий диңгезенең кояш чыгышы тарафында, Иран, Афганистан, Кытай патшалыклары арасындагы җирләргә “Русиянең Урта Азиядәге җире”, “Төркестан” диләр. Төркестанның күп урыны түбәнсу, чүлле тигез җирдер. Көньяк, көньягыннан кояш чыгышы ягына таба якларда Копетдаг, Памир (җирле халыкларча дөньяның түбәсе), Тянь-Шань атлы таулар, тезелгән таулар бар. Бу тауларның кайсыберләренең түбәләре мәңге бер дә бетми торган карлар белән капланган.

Төркестан: Тургай, Акмола, Закаспийский, Сырдарья, Семиреченский, Фергана, Сәмәрканд исемнәрендә 8 областькә бүленәдер. Бу областьләрдән башка, Төркестанда Русия виләятендә Бохара, Хива ханлыклары бар.

Тургай, Семипалат, Акмола областьләренә “Кыргыз далалары” дип тә әйтәләр, чөнки бу областьнең бөтен халкы ялгыз кыргызлардан гына гыйбәрәттер.

Халкы: күчеп килгән руслардан башка, бөтенесе гайре руслар булып, кыргызлар, төркмәннәр, сартлар, таҗиклар, дунганнар. Руслардан башка күбесе мөселманнардыр.



Кыргызларның чатыры


Тормышлары: халыкның тормышы игенчелек, хайван асраучылык, мамыкчылык, бакчачылык, ефәкчелек беләндер. Кыргызларның көн күрүләре ялгыз хайван асраучылык белән генәдер. Аларның беренче байлыклары ат, ике өркәчле тәвә (дөя), куй вә сарыклардыр. Мөгезле хайванны бик күп асрамыйлар. Дөяне авыр йөкләр төяү өчен, атны атланып йөрү һәм аның биясенең сөтеннән сөекле эчемлекләре булган кымыз ясау өчен асрыйлар. Сарык, куйның итен ашыйлар. Йонынынннан йорт, чатыр ясау өчен киез ясыйлар.

Төркестанда игенчелек эше дә бик яхшыдыр. Бигрәк тә Амударья, Сырдарья елгалары тирәсендә туфрак бик бәрәкәтле булганга күрә ашлык бик уңадыр. Бодай, арпа, дөге, тары чәчәләр. Бакчачылык кәсебе игенчелеккә караганда да зурractыр. Авылларның, шәһәрләрнең тирәсе бакчадыр. Виноград, абрикос, персик үсәдер. Басуларда кавын, карбыз, мамык, тәмәке җитешәдер. Төркестанда мамык кәсебе, тимер юл салынганның соңында бигрәк тә алга

китте. Ефәкчелек бу як халкының бик борынгы кәсебедер. Шунлыктан ефәкчелек эше дә яхшы ук урын тотадыр.

Төркестанда фабрика вә заводлар юктыр. Төркестан халкында кул һөнәре хыялый зур урын ала. Ефәк вә җептән төрле материаллар сугалар, паласлар тукыйлар.

Төркестаннан читкә чыга торган маллар: мамык, ефәк, май, тире, коры җимештер.



Сәмәркандта җимеш сәүдәсе

**Атаклы шәһәрләре:** Уральский областендә: Урал елгасы өстендә Гурьев шәһәре областьнең башкаласыдыр. Монда балык сәүдәсе зурдыр.

Тургай областендә: иң зур шәһәр Тургай каласыдыр.

Акмола областендә: Иртыш елгасы өстендә Омски каласыдыр. Степной генерал губернатор монда тора.


Семипалат областендә: Семипалат каласыдыр.

Семиреченский областендә: Верный (Алмата), Копал, Яркент, Пржевальский, Пишпек бу областьнең атаклы калаларыннан.

Областьнең идәрәсе Верныйдадыр. Семиреченский областендә мөселманнар да күптер. Мөселманнар күбрәк шәһәрләрнең бөтенесендә мәчетләр, мәдрәсәләр, мәктәпләр бардыр. Верныйда берсе ирләргә, берсе кызларга махсус ике урта мәктәп (гимназия) бар.

Сырдарья областендә: Ташкент, Төркестан, Казалы, Пироф, Чемкент, Аулие-Ата, Петроалександров, Чимбай – болар областьнең атаклы өяз калаларыннандыр.

Ташкент Сырдарья елгасына кушыла торган Чирчик елгасының уң ярында Урта Азиянең иң төз вә матур шәһәредер. Монда ирләргә вә кызларга махсус урта (гимназия вә реальный) мәктәпләр бар.



Сәмәркандта Ширдар мәдрәсәсе

Сәмәрканд областендә: Сәмәрканд, Хуҗанд, Каттакурган, бу областьтәге атаклы калалардыр. Сәмәрканд Азиянең иң борынгы каласыдыр. Бүгенге көндә бу областьнең мәркәзе. Монда ирләргә һәм кызларга хас гимназияләрдән башка, бакчачылык, виноградчылык мәктәбе, дүрт сыйныфлы шәһәр мәктәбе бардыр.

Сәмәрканд Төркестанда борынгы заманнан бирле мәктәп, мәдрәсәләрнең күплеге белән данлыдыр. Бар заманнарда Сәмәрканд мөселманнарның гыйлем, мәгариф мәркәзләреннән саналмыштыр. Сәмәрканд мәдрәсәләре арасында Биби ханым, Тиллә-Кари, Ширдар, Олуг Бек мәдрәсәләре иң мәшһүрләредер.

Фергана областендә: Маргилан (Скобелев), Коканд, Наманган, Андиҗан, Ош шәһәрләредер.

Забайкальский областендә: Ашхабад, Красноводский, Форд Александрский, Мерв шәһәрләре.

## §47 — Тимер юллар

Русиядә табигый вә сынагый (ясалма) һәртөрле юллар бар. Табигый юллар: параход йөри торган иделләр, диңгезләрдер. Сынагый (әдәмнәр тарафыннан эшләнгән) юллар: каналлар, тимер юллардыр.

Юлларның тизлек, уңайлылык ягыннан иң җайлысы тимер юллардыр. Тимер юлларда теләсә кайсы чакта сәяхәт кылырга, бер җирдән икенче урынга сәүдә малларын китерергә, илтергә мөмкиндер.

Русиядә тимер юл тармакларының иң еш җире Балтыйк вә Кара диңгезләр тирәседер. Беренче тимер юл мәркәзе Мәскәүдер: моннан ун тарафка тимер юл китәдер. Мәскәүдән китә торган тимер юллар Русиянең сәүдәдә алдынгы шәһәрләре һәм Русиядә башка тимер юлларның бөтенесе белән тоташадыр.

Мәскәүдән Петербургка, Ярославль һәм Вологда аркылы Архангельскига, Владимир аша Нижнийга, Рязань аркылы Казанга, Ростов, Дон һәм Владикавказга, Самара вә Себергә, Киев, Курский, Одессага. Харьков аркылы Севастопольгә, Азов диңгезе буендагы Таганрогка, Смоленский, Витебский, Двинский аркылы Ригага китәдер.

Икенче мәркәз Петербургтадыр: моннан Псков аша бер тармак Ригага, шул ук Псковтан икенче тармак Двинский, Вильна, Грудна, Белосток аркылы Варшавага барадыр. Вологда, Вятка, Пермь аша Екатеринбургка китәдер. Выборг аша Финляндиягә, Ревель аша

Балтыйк портына барадыр. Петербургтан бер тармак чыгып Мәскәүгә китәдер.

Өченче мәркәз Варшавададыр: монда Петербургтан, Мәскәүдән, Русиянең көньягы тарафыннан тимер юл тармаклары кушыла. Варшавадан икенче падишаһлыкларга, Пруссиягә вә Австриягә юллар китәдер.

Кавказда Бакудан Тифлис, Кутаис аркылы Кара диңгез буендагы Потига вә Батумга сузылмыштыр. Икенче юл Бакудан Каспий диңгезе буйлап, Дербент, Тимерхан, Шура аша Екатеринодарга китәдер.

Төркестан виләятләрендә ике тимер юл бар. Олуг Себер тимер юлы, Себернең бер читеннән икенче читенә кадәр сузылган. Җиде мең чакрым кадәр озынлыкта, җир йөзендәге иң зур бер тимер юлдыр. Бу тимер юл Чита шәһәреннән узгач, икегә аерылып, бер тармагы Амур елгасы буйлап Владивостокка, икенчесе Манчжурия аркылы Кытай диңгезенә кадәр барадыр.

*Беренче кисәк бетте.*